ДҮШӘМБЕ
22 ГЫЙНВАР
1940 ел
№ 18 (5818)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:
Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

Москва, Кремль

Иосиф Виссарионович Сталинга

Кадерле һәм сөекле юлбашчыбыз һәм остазыбыз!

Бүген, пролетар революциянең даһи стратегы, большевизмның оештыручысы һәм юлбашчысы, хезмәт ияләре массасының дусы һәм остазы—Владимир Ильич Лениннең үлүенә 16 ел тулу көнендә, Казан шәһәренең партия, совет, комсомол һәм профсоюз активының кайгы җыелышы, бөтен дөнья халыклары белән берлектә, Сезнең белән берлектә, иптәш Сталин, үзенең авыр югалтудан булган зур кайгысын уртаклаша. Сөекле һәм якын Ильич бездән киткән көннәрдә, кире кайтмаслык югалтуны бөтен алдынгы кешелек дөньясы йөрәгендә тирән әрнү белән кичергән көннәрдә, Сез, Лениннең турылыклы көрәштәше һәм шәкерте, юлбашчының гробы янында, партия һәм халык исеменнән изге ант бирдегез, Ленин васиятләренә турылыклы һәм бирелгән булырга ант бирдегез.

Сез, партия члены дигән бөек исемне югары тотарга һәм саф итеп сакларга; партиябезнең бердәмлеген күз алмасы кебек сакларга; эшчеләр сыйнфы диктатурасын сакларга һәм ныгытырга; эшчеләр һәм крестьяннәр союзын бөтен көч белән сакларга һәм ныгытырга; Республикалар Союзын ныгытырга һәм киңәйтергә; Кызыл Армиябезне һәм Кызыл Флотыбызны ныгытырга; бөтен дөнья хезмәт ияләренең союзын—Коммунистик Интернационалны киңәйтергә дип партия исеменнән ант бирдегез. Бу бөтен халык исеменнән бирелгән ант иде. Сезнең аркылы миллионнарча кешеләр сөйләде. Сез аларның тирән фикерләрен, аларның өметләрен, аларның сугышчан омтылышларын, аларның бөек Ленин эшен ахрынача җиткерергә хәзер торуларын белдердегез.

Халыкның кабахәт дошманнары — хиянәтчеләр бандасы,—троцкичылар, зиновьевчылар, бухаринчылар, буржуаз милләтчеләр партиягә килгән бу авыр югалтудан үзләренең хиянәтчел максатлары өчен файдаланырга теләделәр. Алар большевикларның ныклы сафларына буталыш, аерылу кертергә, совет халкының казанышларын, аның социализмга булган ышанычын тартып алырга маташтылар.

Сез, Ленин эшен бөек дәвам иттерүче, бу сатлыкларның мәкерле уйларын фаш иттегез, Ленин тагълиматын хиянәтчеләрнең һөҗүмнәреннән саклап калдыгыз, дошманнар тар-мар ителделәр һәм юк ителделәр.

Ленин үлгәннән соң партия Сезнең җитәкчелегегездә Советлар иле халыкларын Ленин юлы белән алып барды һәм гаять зур җиңүләргә ирешкә... кыенлыкларны җиңеп, социализмның хәл иткеч җиңүләренә ирешге. Капиталистик чолганыш шартларындагы социалистик дәүләт турындагы тагълиматны эшләп, Сез, ленинизмны баеттыгыз һәм тирәнәйттегез. Бу тагълимат безнең партиябезне яңа җиңүләр өчен идея ягыннан коралландыра һәм аны оешу ягыннан ныгыта. Совет халкын ышанычлы адымнар белән коммунизмга алып баручы Ленин—Сталин партиясен какшата алырлык көч юк. Социалистик дәүләтнең иҗад тормышын боза алырлык көч юк.

Ленин эше, Ленин идеяләре мәңгелек, чөнки большевиклар партиясенә һәм совет халкына, бөтен дөнья коммунизмына зирәк һәм даһи юлбашчы, иптәш Сталин, Сез җитәкчелек итәсез. Сездә Ленин фикерләре һәм Ленин эшләре гәүдәләнгән. Сездә Лениннең бөтен зирәклеге һәм бөеклеге гәүдәләнгән. Сталин—ул, бүгенге Ленин. Совет халкы, геройлар халкы, Сезгә чиксез ышана һәм Сезнең җитәкчелегегездә, Ленин—Сталин партиясе җитәкчелегендә, ышанычлы адымнар белән алга, коммунизмның яңа җиңүләренә таба бара.

Яшәсен Ленинизм!

Яшәсен Ленин—Сталин партиясе!

Яшәсен Ленин эшен бөек дәвам иттерүче, акыллы остазыбыз, туган атабыз һәм юлбашчыбыз Иосиф Виссарионович СТАЛИН!

КАЗАН ШӘҺӘР АКТИФЫНЫҢ В. И. ЛЕНИННЕҢ ҮЛҮЕНӘ 16 ЕЛ ТУЛУГА БАГЫШЛАНГАН КАЙГЫ ҖЫЕЛЫШЫ

21 нче гыйнвар!

Менжинский исемендәге клубның зур залы төрле профессия кешеләре белән тулган. Аларның күзләре, әледән-әле, гөлләр белән төрелгән постамент өстендәге кызыл бархет байрак белән уралган рәсемгә текәлә. Бу рәсемгә карау белән алар, үзләре дә сизмәстән, тирән уйга чумалар. Аларның йөрәкләре кысыла, сыкрый, әрни, тын алулары ешая башлый. Әле шушы минутта гына, ниндидер зур—бик зур югалту булган кебек тоела аларга.

Бу рәсем—бөтен алдынгы кешелекнең бөек даһие, Маркс—Энгельс байрагын югары күтәрүче, көрәштә җиңүдән башканы белмәгән һәм белми торган героик коммунистлар партиясен төзүче, Бөек Октябрь Социалистик Революциясенең җиңүләрен оештыручы, бөек кеше—Владимир Ильич Ленин рәсме. Бу бөек һәм гүзәл кешенең йөрәге тибүдән туктауга инде 16 ел тулды.

Бүген илебезнең барлык почмакларында, барлык шәһәрләрендә һәм барлык авылларында бөек Лениннең безнең арабыздан югалуына багышланган кайгы җыелышлары бара.

Бу залда утыручылар партия, совет, комсомол һәм профсоюз активлары. Алар бергә кайгы җыелышына килгәннәр.

ВКП(б) ның Казан Шәһәр Комитеты секретаре иптәш Нацыбуллин җыелышны ачык дип белдерә. Җыелышның президиум составына ВКП(б) ның Өлкә Комитеты секретарьлары Алемасов, Матвеев, Долатказин иптәшләр Татарстан Халык Комиссарлары Советы председателе иптәш Тынчеров, Татарстан Верховный Советы Президиумы председателе иптәш Динмөхәметов, ВКП(б) ның Казан Шәһәр Комитеты секретарьлары Бычков һәм Нацыбуллин иптәшләр, СССР Халык Комиссарлары Советы янындагы Совет Контроле Комиссиясе уполномоченные Рундаев, Казан Шәһәр Советы Башкарма Комитеты председателе иптәш Мурин һәм башкалар сайландылар.

Почетлы президиумга, бөек юлбашчыбыз һәм сөеклебез иптәш Сталин, аның иң якын көрәштәшләре Молотов, Ворошилов, Каганович, Калинин, Андреев, Микоян, Жданов, Хрущев, Берия, Шверник иптәшләр һәм иптәш Тельман сайлана.

Җыелышта партиянең Казан Шәһәр Комитеты секретаре иптәш Бычков, „Иптәш Сталин җитәкчелегендә Ленин юлы белән Лениннән башка 16 ел“ дигән темада доклад ясады. Ул үзенең докладында бөек Лениннең эшен туктаусыз дәвам иттерүче, бүгенге көннең Ленинне—бөек Сталин җитәкчелегендә шушы узган 16 ел вакыт эчендә СССР халыклары яулап алган гүзәл казанышлар турында тулы итеп сөйләде. Докладчы, шушы 16 ел эчендә илебезнең экономик-политик һәм оборона куәте гаять нык үсүе турында, барлык милләт халыкларының формасы белән милли, эчтәлеге белән социалистик культуралары чәчәк атуы турында аеручa тукталып үтте. Ул данлыклы Кызыл Армиябез һәм хәрби һава көчләребез турында һәм бу данлыклы армия тарафыннан хәзерге вакытта алып барыла торган азатлык көрәше турында әйтеп үтте.

Докладтан соң җыелыш зур күтәренкелек белән иптәш Сталинга хат кабул итте. Шуның белән актив җыелышы тәмам булды.

ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫНЫҢ ОПЕРАТИВ СВОДКАСЫ

20 нче гыйнварда фронтта әһәмиятле бер нәрсә дә булмады.

Безнең авиация күп кенә районнарда уңышлы рәвештә бомбага тотулар үткәрде. Һава бәрелешләрендә дошманның 15 самолеты бәреп төшерелде.



РӘСЕМДӘ: „В. И. Ленин крестьян вәкилләрен кабул итә“. Москва шәһәрендә сынлы сәнгать музеендәге художник Игорь Грабарь рәсменнән. (ТАСС фото-клишесе).

В. И. Лениннең хезмәтләрен бастырып чыгару

ВКП(б) Үзәк Комитеты янындагы Маркс—Энгельс—Ленин институты В. И. Лениннең сайланма әсәрләре икетомлыгының яңа басмасын чыгара. Икетомлыкта бөтен материал „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“на туры китереп урнаштырылган.

Ленин көннәренә Госполитиздат В. И. Ленин китабын бастырып чыгарды. Бу китапка Ленин тарафыннан 1923 нче елда язылган: „Көндәлектән сәхифәләр“, „Кооперация турында“, „Безнең революция турында“, „Безгә Рабкринны ничек үзгәртеп оештырырга“, „Аз булса да яхшы булсын“ дигән мәкаләләре кертелгән. Китап 100 мең данә тиражда басылган.

В. И. Лениннең 1905 нче ел 9 нчы гыйнвар вакыйгаларенә багышланган мәкаләләре җыентыгы „9 нчы гыйнвар“ исемендә массовый тиражда чыгарылды. Шулай ук, Владимир Ильич Лениннең Совет илен империалистик державалар һөҗүменнән саклауга, 1918—1920 нче елларда интервенцияне һәм эчке контрреволюцияне тар-мар итүне оештыруга багышланган мәкаләләре, речьләре һәм эшчеләргә, кызыл армеецларга мөрәҗәгатьләре җыентыгы да чыгарылды. Бу җыентыкның тиражы—300 мең данә.

(ТАСС).

В. И. ЛЕНИННЕҢ ЯҢА ДОКУМЕНТЛАРЫ

В. И. Лениннең түбәндә басыла торган документларыннан беренчесе, 1913 нче елның мартында язылганы, гади дәфтәр форматындагы 9 биткә язылган кульязмадан гыйбарәт. Кульязмага заголовок куелмаган. Бу, нефть бәясен арттырган нефть синдикаты турында думада тикшерелгән мәсьәлә уңае белән IV нче Дәүләт Думасы трибунасыннан большевик депутатларның чыгышлары өчен проект булса кирәк. Лениннең бу кульязмасы нефть турындагы конкрет мәсьәләдә, иске патша Россиясенең элекке хаким сыйныфларының—капиталистларның һәм алпавытларның талау политикасын гаять ачык формада фаш итә. Россиядәге нефть синдикаты турында, Америкада нефть җитештерү һәм нефть бәясе турында моннан элек иглан ителгән Ленин материаллары („Ленинский сборник“ның XXIX нчы томын карагыз, 446—447 нче битләр) шушы документка турыдан-туры кагылалар.

Икенче документ рус теле сүзлеген төзү турындагы зур политик һәм фәнни әһәмияте булган мәсьәләгә багышланган. 1920—21 нче елларда Владимир Ильич бу мәсьәләгә берничә тапкырлар яңадан кагылып, Наркомпрос работникларыннан рус теле сүзлеген (Пушкиннан алып Горькийга кадәр), үрнәк булырлык, хәзерге заманча, яңа орфография буенча сүзлек төзү эшен тизләтүне таләп итте („Ленинский сборник“ның XX һәм XXIII нче томнарында иглан ителгән язышуны карагыз). Документ Эшче һәм Крестьян Оборонасы Советы Председателе бланкысына язылган.

Өченче документны—„1 нче дәүләт автомобиль заводының завкомына һәм барлык эшчеләренә“ дигән кульязманы Ленин завод завкомының хатына язган. Бу хатта эшчеләр Владимир Ильичны беренче двигательләр эшләнеп чыгу белән котлаганнар һәм аны шул уңай белән 1921 нче елның 7 нче апрелендә сәгать 1 гә билгеләнгән завод бәйрәменә катнашырга чакырганнар. Үзенең котлавын эшчеләр вакытында алсыннар өчен Владимир Ильич телефонограмманың өстенә „12 сәгатьтә тапшырырга“ дип язган һәм аның астына берничә кат сызган. Лениннең котлавы 1921 нче елның 7 нче апрелендә завод митингысында укылган.

ВКП(б) Үзәк Комитеты янындагы Маркс—Энгельс—Ленин Институты.

„Нефть кытлыгы“ турындагы мәсьәлә

„Нефть кытлыгы“ турындагы, нефтьнең чиксез кыйммәтләнүе турындагы, кулланучыларны талау өчен тузларның—нефть промышленникларының җинаятьле стачкасы турындагы мәсьәлә Думада, ә аннан да бигрәк Думадан тыш бик законлы кызыксыну һәм аңлаешлы ачу китереп чыгарды.

Синдикатчыларны — нефть корольләрен бик аз гына яшерен формада **яклаган** сәүдә һәм промышленность министре әфәнде белән хөрмәтле крепостникларның—алпавытларның җәберләнү хисләрен көчле һәм ялкынлы төстә чагылдырган Марков 2 әфәнде арасындагы дуэль, бу дуэль (22 нче мартта Дәүләт Думасы утырышында) эшчеләр сыйнфының һәм бөтен демократиянең иң ныклы игътибарын үзенә тарта. Бу дуэль Россиядәге ике „хаким“ сыйнфның, „югары“ дип атала торган (ә чынлыкта бик түбән, әшәке, талаучы булган) ике сыйныфның, крепостник—алпавытлар сыйнфы белән финанс тузлары сыйнфының барлык үз ара мөнәсәбәтләрен бик ачык күрсәтә.

Нефть синдикаты турындагы мәсьәлә беренче карауда частный мәсьәлә булып күренә. Ләкин бу алай түгел. Чынлыкта бу—бары тик ике хаким сыйныфның Россияне идарә итүе турындагы (яки, дөресрәге, Россияне талау турындагы) гомуми һәм төп мәсьәләнең күренешләреннән берсе. Марков 2 нең речe, табышны бүлгәндә кимсетелгән ЗУБР күзлегеннән караганда, нефть „корольләрен“ яклаучыга бик шәп җавап бирде. Бу вакытта Марков 2 әфәнденең „үз-үзенә карый“ белмәгән булуы, күзгедә үзен (һәм үзенең дусларын—алпавытларны) күрә белмәгән булуы гаҗәп түгел. Мин Марков 2 әфәндегә хезмәт күрсәтергә тырышып карармын; мин аның алдына көзге куярмын. Мин аңа аның рәсемен ясармын. Мин Марков 2 нең һәм Хвостовның нефть корольләре белән, керосин синдикаты тузлары белән, Баку миллионерлары белән „талашулары“ өйдәге талашу, халык байлыгын ике урлаучының талашуы икәнлекне күрсәтермен. „Дуслар талашу белән күңел ачалар“. Бер яктан министр әфәнде һәм компаниясе белән Нобель әфәнде, икенче яктан үзләренең сенаттагы Дәүләт советындагы һ. б. дуслары белән Хвостов һәм Марков әфәнделәр, болар—„**дуслар**“. Ләкин бу дус һәм җылы компания аркасында Россиядәге уннарча миллион эшчеләргә һәм таланган крестьяннәргә авырлык бик артык төшә шул!

Нефть мәсьәләсенең үзәге нәрсәдә?

Барыннан да элек, нефтьче әфәнделәрнең скважиналарда һәм заводларда эшләп чыгаруга ясалма тоткарлык тудыру өстенә бу капиталистик табыш „рыцарьлары“ ның нефть бәясен оятсыз рәвештә күпертүләрендә.

Бу пунктларга кагыла торган төп саннар Думада китерелделәр инде, ләкин шулай да мин үземнең түбәндәге сүзләремне тәмам ачык итү өчен бу саннарны кыскача гына кабатларга тиешмен. 1902 нче елны нефтьнең поты 6 тиен иде. 1904 нче елны 14 тиенгә кадәр күтәрелә. Аннары бәяләрнең „сикереше“ тагын да „күңеллерәк“ булып китә, шулай итеп, бишенче ел революциясеннән соң 1908—09 нчы елга бер потның бәясе 21 тиенгә кадәр, ә 1912 нче елга **38 тиенгә кадәр** җитә.

Шулай итеп, 10 ел эчендә бәя **алты тапкырдан күбрәк** арткан! Ә шул вакыт эчендә нефть чыгару 1900—1902 нче еллардагы 600—700 миллион поттан 1908—1912 нче елларда 500—585 милион потка кадәр **кимегән**.

Бу саннарны хәтерләрлек бар. Алар турында уйларга кирәк. Ун ел эчендә бөтен дөньяда нефть чыгару гаять зур сикерешләр белән югары күтәрелгәндә һәм бәяләр **алты тапкырдан күбрәк** артканда нефть чыгару кими.

Сәүдә һәм промышленность министре әфәнде, сүз куешкан сәүдәгәрләрне һәм промышленникларны яклап, акылга сыймаслык дәрәҗәдә кызганыч булган йомгаклар ясады.

Ул әйтте: ягулыкка сорау үсә, автомобил һәм авиация промышленностының нефтькә соравы үсә, бу — „бөтен дөнья“ күренеше диде, сезне һәм рус халкын министр әфәнде шулай дип юатты.

Ярый, ә Америкада? — дип сорыйбыз без. Мондый сорау үзеннән-үзе килеп чыга, чөнки безгә мәгълүм, Америка — нефть җитештерү буенча Россиянең бердәнбер җитди конкуренты. 1900 нче елны Россия һәм Америка икесе бергә бөтен дөньяда чыгарылган нефтьнең 9/10 өлешеннән артыгракын, ә 1910 нчы елны 8/10 өлешеннән артыгракын бирделәр.

Әгәр дә сүз „бөтен дөнья“ күренеше турында барса иде, министр әфәнде, димәк, Америкада да **шундый ук** хәл булырга тиеш? Һәм менә шуннан соң, сүз куешкан талаучы нефтьчеләрне яклаучы министр әфәнде, игътибар белән тыңламаучыларда **тәэсир** калдыру өчен, Америка турындагы саннарны китерде... **Ләкин 2 елга карата гына!!** Соңгы ике ел эчендә Америкада нефть бәясе ике тапкыр күтәрелгән, Румыниядә дә шулай ук.

Бик яхшы, министр әфәнде! Ләкин ни өчен соң чагыштыруны ахрына кадәр җиткермәскә? Чагыштыргач чагыштырырга кирәк. Саннар уены уйнамаска кирәк. Россия турындагы саннар кайсы вакыт өчен китерелгән булсалар, Америка турында да **шул ук вакыт өчен** алырга кирәк. Моның статистиканы вөҗдан белән һәрбер куллануның иң төп, иң элементар, иң гади шарты икәнлеге ачык күренеп тормыймыны?!

10 ел эчендә Россиядә бәяләр министр әфәнденең үзе тарафыннан китерелгән 1902 нче елгы иң түбән бәя белән чагыштырганда **алты тапкырдан** күбрәк күтәрелгән. Ә Америкада? Анда **мондый** артуга охшаган бер нәрсә дә булмаган. 1900 нче елдан 1910 нчы елга кадәр Америкада бәя **кимегән**. Соңгы елларда бәя тигез торган.

Димәк, нәтиҗә нинди? Америкада ике өлеш һәм Россиядә **алты өлеш**. Ә нефть чыгару 1900 нче елны Америкада Россиядәгедән **кимрәк**, ә 1910 нчы елны Россиядәгегә караганда **өч тапкыр артыграк** булган!!

Миллионер нефтьчеләрнең стачкасын килешсез яклаучы министр әфәнде моны әйтергә теләмәде. Ә факт күз алдында. Сез нинди генә саннарны алып карасагыз да, соңгы 10 ел эчендә Америкада кыйммәтләнүнең Россиядә булганга караганда **чагыштырмаслык ким** булганлыгы, нефть чыгаруның исә **гаять дәрәҗәдә** үскәнлеге, ә Россиянең хурлыклы төстә тукталып калганлыгы һәм хәтта артка таба атлаганлыгы шиксез булачак.

Хәзер министребезнең кыйммәтләнүне „бөтен дөнья“ күренеше дип әйтүендә хаклыкның никадәр аз икәнлеген һәм хаксызлыкның никадәр күп икәнлекне без шунда ук күрәбез. Әйе, кыйммәтләнү һәр кайда да бара. Әйе, аны китереп чыгара торган гомуми капиталистик сәбәпләр бар.

Ләкин Россиядә хәл нак менә шуның өчен **түзә алмаслык** ки, чөнки бездә кыйммәтләнү нак менә нефтькә карата үлчәүсез көчлерәк, ә җитештерүнең үсүе урнына туктап тору. Россиядә хәл нак менә шуның өчен **һич тә түзә алмаслык** ки, чөнки капитализмның киң, иркен, тиз үсеше урнына без туктап тору һәм черү күрәбез. Шуңа күрә дә шул ук кыйммәтчелек бездә йөз тапкырлар зарарлырак.

Россиядә халык 170 миллион, ә Америкада 90 миллион, ягъни яртыдан аз гына артыграк. Нефть исә хәзер Америкада бездәгедән **өч тапкыр** күбрәк, ә таш күмерне **ун сигез тапкыр** күбрәк чыгаралар. Америкада тормыш дәрәҗәсе, эшчеләрнең хезмәт хаклары ягыннан караганда, Россиядәгедән **дүрт тапкыр** югарырак.

Министр әфәнденең бу начарлык—бөтен дөнья күренеше дигән сүзләрендә нинди ачык күренеп торган хаксызлык барлыгы ачык түгелме? Бу начарлык Россия өстенә, ун тапкыр булмаса да, дүрт тапкыр **авыррак** төшәчәк.

Ип. Луначарский

Күптән түгел миңа—кызганычка каршы һәм минем оятыма каршы беренче тапкыр,—Дальның атаклы сүзлеге белән танышырга туры килде.

Бик һәйбәт әйбер, ләкин бу **өлкәләр** сүзлеге искергән бит. **Чын** рус теле сүзлеге, әйтик, Пушкиннан алып Горькийга кадәр **хәзер классиклар тарафыннан да** кулланыла торган сүзләрнең сүзлеген төзергә вакыт түгелме.

Әгәр бу эшкә, кызыл армеецлар паегы биреп, 30 галимне утыртсак ничек булыр икән?

Бу фикергә Сез ничек карар идегез?

Классик рус теле сүзлегенә?

Авырсынмасагыз, бик тавышланмый гына, бу мәсьәләне белгән кешеләр белән сөйләшеп карагыз һәм Үзегезнең фикерегезне миңа белдерегез.

18.1.20. Сезнең Ленин.

ТЕЛЕФОНОГРАММА.

1 нче дәүләт автомобиль заводының завкомына һәм барлык эшчеләренә

Кадерле иптәшләр! Мин двигательләр эшләнеп чыгу турында Сезнең завком председателе иптәш Смирновтан белдерү һәм 7.IV бәйрәменә чакыру алдым.

Сезне, иптәшләр, эшегездәге уңыш белән һәм автомобиль механиклары курсларының еллыгы белән котлыйм. Чын күңелемнән күтәренке күңел белән эшләвегезне телим, бу эш, һич шиксез, тагын да уңышлар китерер. Барлык эшчеләр һәм крестьяннәр массасы күзеннән караганда Сезнең уңышларыгызның әһәмияте бигрәк тә зур, чөнки Россиядә нефть күп булган шартларда, двигательләр җитештерүнең үсүе крестьян хуҗалыгын арзанлы һәм практичный двигательләр белән тәэмин итү эшен җайга салырга мөмкинлек бирәчәк. Двигательләр җитештерү эшендә ничек кенә итеп булса да тагын һәм тагын уңышларга ирешергә кирәк.

Иң яхшы теләкләр һәм коммунистик сәлам.

7 апрель 1921 ел. *Ленин.*

„Правда“, 21/1—40 ел.

ЛЕНИННӘН БАШКА, ЛЕНИН ЮЛЫ БЕЛӘН 16 ЕЛ

Моннан 16 ел элек заманыбызның иң бөек кешесе, фикер титаны, пролетар революциянең даһи стратегы, большевиклар партиясен, социалистик революцияне оештыручы һәм аның юлбашчысы, бөтен дөнья хезмәт ияләренең юлбашчысы—Владимир Ильич Лениннең йөрәге тибүдән туктады.

Ленин большевиклар партиясен төзеде һәм утыз ел буена диярлек аны тәрбияләп үстерде. Бөтен дөнья коммунизм хәрәкәтенең башында торучы партиябезне Ленин Өч революция тәҗрибәсендә чыныктырды.

Яңа тип революцион партияне оештыру өчен көрәштә, патша заманындагы подпольенең авыр шартларында, бөек Октябрь штурмы чорында, гражданнар сугышының авыр чорында—Лениннең турылыклы дусты һәм көрәштәше, Ленин эшләрен лаеклы кабул итеп алучы һәм бөек дәвам иттерүче Сталин һәр җирдә дә һәм һәр вакытта да Ленин белән бергә кулга-кул тотышып барды. Ильич үлгәннән соң Ленин байрагын иптәш Сталин үз кулына алды. Бу байракны ул югары күтәрде һәм партияне, эшчеләр сыйнфын, бөтен совет халкын Ленин юлы белән, коммунизмның гаять зур җиңүләре юлы белән алып барды. Социалистик төзелешнең гаять бөек уңышлары—Ленин идеяләренең, Ленин васиятләренең, В. И. Ленин үзенең бөтен тормышын багышлаган революцион эшнең тантанасы.

Ленин идеяләре тормышка ашырылды. Үткән 16 елның хәл иткеч йомгагы илебездә коммунизмның беренче фазасының—социализмның нигездә төзелгән булуыннан гыйбарәт. Барлык эксплоататор сыйныфлар тәмам бетерелделәр, кешенең кешене эксплоатацияләвен һәм җәмгыятнең эксплоататорларга һәм эксплоатацияләнүчеләргә бүленүен тудыручы сәбәпләр мәңгелеккә юк ителде. Социализмның бөтен дөнья күләмендә тарихи әһәмияте булган бу казанышлары Сталин Конституциясендә—капиталистик коллык богауларын алып ташлаган ирекле халыкның бөек хартиясендә закон тәртибендә беркетелде.

Аерым алынган бер илдә социализм төзүнең мөмкинлеге турындагы таглимат марксизм хәзинәсенә Ленин керткән гаять кыйммәтле хәзинә. Бөек Ленин эшен дәвам иттерүче иптәш Сталин Ленин таглиматын теоретик яктан эшләп, аны тагын да алга җибәреп һәм революция дошманнарына, троцкичы - зиновьевчы - бухаринчы лагердан булган хиянәтчеләргә каршы рәхимсез көрәштә аны саклап кына калмады, бәлки, илебездә социализмның җиңүен оештырып, Ленин таглиматын тормышка да ашырды.

1924 нче елның 26 нчы гыйнварында Советларның II нче Бөтенсоюз съездының кайгылы утырышында иптәш Сталин Ленин гробы янында партия исменнән бөек ант бирде.

Иптәш Сталин әйтте:

„Без, коммунистлар, үзенә аерым калып кешеләре. Без махсус материалдан төзелгәнбез. Без—пролетариатның бөек стратегының армиясен, иптәш Ленин армиясен тәшкил итүчеләр. Бу армиядә тору дәрәҗәсенә ирешүдән дә югары һичбер нәрсә юк. Нигез салучысы һәм җитәкчесе иптәш Ленин булган партиянең члены дип аталудан да югары һичбер нәрсә юк...

Иптәш Ленин бездән киткәндә, безгә, партия члены дигән бөек исемне югары тотарга һәм саф итеп сакларга васият итте. Ант итәбез сиңа, иптәш Ленин, без синең бу васиятеңне намус белән үтәрбез!..

Иптәш Ленин бездән киткәндә, безгә, партиябезнең бердәмлеген күз алмасы кебек сакларга васият итте. Ант итәбез сиңа, иптәш Ленин, без синең бу васиятеңне дә намус белән үтәрбез!“

Үткән 16 ел, Сталин җитәкчелегендәге партиянең бу антны намус белән үтәгәнлеген күрсәтте.

Ленин үлгәннән соң, явыз хиянәтчеләр—троцкийлар, зиновьевлар, бухариннар, рыковлар һәм аларга ошашлы башкалар барсы да, ничек кенә булса да партияне аерырга һәм шуның белән илебездә җиңүле социалистик төзелеш эшен өзәргә маташып партиягә үзләренең атакаларын ун тапкыр арттырдылар. Бу хиянәтчеләр партиягә каршы үзләренең көрәшләрендә, партиягә һәм аның кадрларына яла ягудан башлап, почмактан торып үтерүләргә кадәр, үзләренең агулы коралларының барлык төрләреннән файдаландылар. Ләкин Ленин төзегән партияне, Сталин җитәкчелек итә торган партияне бер нәрсә дә какшата алмады. Ленин—Сталин партиясе, халык дошманнарын тар-мар итеп һәм үзенең сафларын чит ил разведкалары шпионнарыннан һәм перерожденецлардан тазартып, тагын да ныграк, сугышчанрак һәм бердәмрәк булып әверелде. Большевикларның бөек партиясе үзенең данлыклы Үзәк Комитеты тирәсенә, үзенең зирәк юлбашчысы—Сталин тирәсенә бүген элеккедән дә ныграк тупланды.

Ленин—Сталин партиясенә барлык совет халкының ышанычы элеккедән дә зуррак. Социализм юлына баскан ун миллионнарча партиясез эшчеләр, колхозчылар һәм совет интеллигенциясе партия артыннан бара.

Марксизм-ленинизм таглиматы бөек көч булып әверелде. Ленин һәм Сталин партияне революцион теория белән коралландырдылар. Ленин—Сталин таглиматы тормышта акланды. Ленин—Сталин таглиматы белән без коммунизмның тулы җиңүенә килербез.

Идея-теория эше гаять дәрәҗәдә үсте. Бездә марксизм-ленинизм пропагандасы чын мәгънәсе белән дәүләт колачы алды. Миллионнарча партияле һәм партиясез большевиклар „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“н. һәм Маркс, Энгельс, Ленин, Сталин әсәрләрен тирәнтен өйрәнүгә керештеләр. Гомумән партиянең һәм аерым алганда һәрбер коммунистның авангардлык роле бик нык үсте. Партия члены дигән бөек исем әлегәчә булмаган югарылыкка күтәрелде.

Моннан 16 ел элек иптәш Сталин биргән антта әйтелә:

„Иптәш Ленин бездән киткәндә, безгә, пролетариат диктатурасын сакларга һәм ныгытырга васият итте. Ант итәбез сиңа, иптәш Ленин, синең бу васиятеңне дә намус белән үтәү өчен без көчләребезне кызганмабыз!“.

Пролетариат диктатурасы—марксизм-ленинизм таглиматында төп мәсьәлә. Ленин—Сталин партиясе җитәкчелегендә эшчеләр сыйнфы, Бөек Октябрь Социалистик Революциясенең җиңүе нәтиҗәсендә пролетариат диктатурасын урнаштырып, социализмның бөтен дөнья күләмендә тарихи әһәмияте булган җиңүләренә ирешите.

Ленин гробы янында биргән антында иптәш Сталин әйтте:

„Иптәш Ленин бездән киткәндә, безгә, эшчеләр һәм крестьяннәр союзын бөтен көч белән ныгытырга васият итте. Ант итәбез сиңа, иптәш Ленин, без синең бу васиятеңне дә намус белән үтәрбез!“.

Үткән 16 ел, Сталин җитәкчелегендәге партиянең бу антны да намус белән үтәгәнлеген күрсәтте.

Пролетариат диктатурасының нигезе эшчеләр сыйнфының крестьяннәр белән союзыннан, җитәкчелек роле пролетариат кулында булган союздан гыйбарәт. Бу союзны ныгыту һәм пролетариатның җитәкчелек ролен көчәйтү өчен, беренче чиратта, эшчеләр сыйнфының позицияләрен һәм вак товарлыклы индивидуаль хуҗалыктан җәмагатьләштерелгән, социалистик эре хуҗалыкка күчүне тормышка ашыруда эшчеләр сыйнфының крестьяннәргә булышлык итүенә мөмкинлек бирә торган материаль базаны ныгытырга кирәк иде. Илне Сталинчыл социалистик индустрияләштерү планы белән бу тарихи бурыч бик яхшы итеп үтәлде. Илне индустрияләштерү буенча партиянең XIV нче съездында иглан ителгән политика, гаять зур кыенлыкларга да карамастан, зур эзлеклелек белән тормышка ашырылып килде. Нәтиҗәдә безнең илебез, производство техникасы һәм промышленностьның үсеш темплары ягыннан төп капиталистик илләрне узып китте, артта калган аграр илдән беренче класслы индустриаль ил булып әверелде.

1938 нче елны ук инде безнең илебез промышленность продукциясенең гомуми күләме ягыннан, машина төзелеше буенча, тракторлар, йөк автомобильләре җитештерү, тимер рудасы чыгару һәм башкалар буенча Европада беренче урынга чыкты. Авыл хуҗалыгы машиналары җитештерү һәм комбайннар эшләп чыгару буенча без Европада гына түгел, бөтен дөньяда да беренче урынны алдык. Беренче һәм икенче бишьеллыклар елларында социалистик промышленность гигантлары төзелде. Безнең индустрия гигантларыбызның җиһазлары—дөньяда иң яңалар һәм иң яхшылар.

Икенче бишьеллык ахрында без эшләп чыгарган бөтен промышленность продукциясенең 80 процентан артыграгы беренче һәм икенче бишьеллыклар елларында салынган яки баштан аяк үзгәртеп корылган фабрикаларда һәм заводларда эшләнде. Сталинчыл бишьеллыклар Советлар илен көчле һәм җиңелмәслек иттеләр.

Социалистик индустрияләштерүнең бу гүзәл җиңүләре хезмәт җитештерүчәнлегенең үсүе белән, кадрларны кадерләп үстерү белән, халыкның материаль тормыш дәрәҗәсенең системалы рәвештә һәм өзлексез күтәрелүе белән бергә барды. Шушы нигездә, иске техник нормаларны ватучы һәм әлегә кадәр күрелмәгән, яңа, югары хезмәт җитештерүчәнлеге бирүче, куәтле стахановчылык хәрәкәте туды.

Болар барсы да партиянең XVIII нче съездына илебез алдына бөтен дөнья күләмендә тарихи әһәмияте булган бурычны куярга мөмкинлек бирделәр: якындагы 10—15 ел эчендә төп капиталистик илләрне экономик яктан да узып китәргә. Партиянең XVIII нче съездының карарлары Сталинчыл Өченче Бишьеллык исмендәге социалистик ярышның яңа күтәрелешен китереп чыгарды. Шушы нигездә алдынгы стахановчылар һәм ударниклар үз араларыннан күп станокларда эшләүчеләрне үстерделәр, берничә профессиядә бер юлы эшләүне куллана башладылар.

Промышленностьның үсүе белән бергә илебезнең эшчеләр сыйнфы да ныгыды. 1939 нчы ел башына инде эшчеләр һәм хезмәткәрләр саны 28 миллион кешегә җитте. Партия тарафыннан җитәкләнүче эшчеләр сыйнфы илебезнең крестьяннәренә эре колхоз производствосына күчүне тормышка ашырырга һәм шуның белән пролетариат диктатурасын тагын да ныгытырга ярдәм итте.

Милионнарча крестьян хуҗалыкларын колхозлар юлына күчерү, авыл хуҗалыгын социалистик реконструкцияләү пролетар революциянең иң кыен бурычы иде. Ләкин бу бурычны хәл итми торып капитализмның тамырларын корытырга мөмкин түгел иде, чөнки алар вак товар производствосына нигезләнгәннәр иде. Бездә әле вак крестьян производствосы өстен булып килгәндә без капитализмның тамырларын өзә алмаячакбыз һәм капитализм өчен экономик база коммунизм өчен булганга караганда күп ныграк булып калачак дип Ленин берничә тапкырлар аеруча күрсәтте.

Илне социалистик индустрияләштерү бу бөек бурычны хәл итү өчен авыл хуҗалыгын яңа техника белән кирәгенчә коралландыруны тәэмин итте.

1929 нчы елның җәеннән башлап бөтен илдә массовый колхоз хәрәкәте җәелеп китте. Партия, иптәш Сталин күрсәтмәсе буенча, массовый колхоз хәрәкәтенә таянып, үзенең политикасында текә борылыш ясый: ул кулакларны чикләү һәм кысрыклау политикасыннан тоташтан коллективлашу нигезендә кулакларны сыйныф булу ягыннан бетерү политикасына күчү лозунгысын куя. „Бу—гаять тирән революцион борылыш, җәмгыятнең иске сыйфат хәленнән яңа сыйфат хәленә сикереш иде, үзенең нәтиҗәләре буенча 1917 нче елның октябрендәге революцион переворотка тиңләшә торган сикереш иде.“ („ВКП(б) тарихының кыскача курсы“, 344 бит).

Авылны социалистик үзгәртеп кору өчен, иген уңышын күтәрү өчен, бөек Сталин җитәкчелегендә үткәрелгән гаять зур иҗади көрәш авыл хуҗалыгын тарихта булмаган җиңүләргә китерде.

Хәзер хуҗалыкта социалистик система безнең игенчелегебезнең бердәнбер формасы. 1938 нче елны бездә 242.400 колхоз булды, алар барлык крестьян хуҗалыкларының 93,5 процентын һәм барлык чәчүлек мәйданнарының 99,3 процентын берләштерделәр. Бу саннарда партиянең гаять зур җиңүе—колхозларның тәмам ныгуы һәм шуның белән илебездә капитализмның экономик җирлегенең юк ителүе чагылган.

Моннан 20 ел элек, 1919 нчы елны, партиянең VIII нче съездында Ленин болай диде: „Әгәр дә без иртәгә беренче дәрәҗәдәге 100 мең трактор бирә алсак иде һәм аларны бензин белән тәэмин итә алсак, аларны машинистлар белән тәэмин итә алсак иде (сез бик яхшы беләсез, хәзергә бу әле фантазия), ул чакта урта хәлле крестьян: „Мин коммуния яклы“ (ягни коммунизм яклы) дияр иде“. Хәзер инде Лениннең бу хыялы тормышка ашырылды. 1938 нче ел ахрында социалистик авыл хуҗалыгында 483.500 трактор булды. Бөтен тракторлар паркының куәте 9 миллион 25 мең ат көчендә булды. Колхоз һәм совхоз кырларында 153.792 комбайн эшләде. Бездә комбайннар саны Америка Кушма Штатларында булганга караганда ике тапкыр күбрәк. Авыл хуҗалыгында 195.800 йөк автомобиле, 83.800 эчке янулы двигательләр һәм локомобильләр бар.

Илебезнең алдынгы техника белән коралланган, дөньяда иң эре булган авыл хуҗалыгы үзенең продукт бирүен елдан-ел арттыра. Колхоз-совхоз игенчелеге хәзер Сталин куйган бурычны—ел саен 8 миллиард пот ашлык җитештерү бурычын хәл итә. Бөтен СССР да гектардан 100 пот бөртекле ашлык алу өчен ярыш җәелә. Ферганә мамыкчылары инициативасы ирригация төзелешендә бик матур нәтиҗәләр бирде.

Авыл хуҗалыгы хезмәте индустриаль хезмәтнең бер төре булып әверелә.

Кулакларга һәм аларның агентурасына—уң һәм „сул“ перерожденецларга каршы каты көрәшләрдә эшчеләр сыйнфының крестьяннәр белән союзы—эшчеләр сыйнфы диктатурасының нигезе ныгыды һәм чыныкты. Социализмның бөек җиңүләре, илебезнең йөзен тамырыннан үзгәртеп, Советлар Союзы халкының сыйнфи составын да үзгәрттеләр, эшчеләр сыйнфының, крестьяннәрнең, интеллигенциянең йөзен үзгәрттеләр. СССР хезмәт ияләре арасындагы сыйнфи чикләр җуела, аерым сыйныфларның элекке өстенлекләре югала. „СССР тормышында булган бу тирән үзгәрешләр, СССР да социализмның бу хәл иткеч уңышлары СССР ның яңа Конституциясендә гәүдәләнделәр“. („ВКП(б) тарихының кыскача курсы“, 388 бит).

Безнең Ватаныбызда Сталин Конституциясе байрагы астында булган кебек чын демократиянең чәчәк атуы кешелек тарихында әле булганы юк иде. Сталин Конституциясендә, җиңеп чыккан социализмның казанышлары язылган. Кешенең кешене эксплоатацияләве бетерелде, хезмәткә, ял итүгә, белем алуга, картлыкта тәэмин ителүгә хокук гарантияләнде. Социалистик демократия җиңеп чыкты. СССР Верховный Советына, союзный һәм автономияле республикаларның Верховный Советларына һәм хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлаулар совет халкының какшамаслык мораль - политик бердәмлеген, коммунистлар һәм партиясезләр блогының гүзәл җиңүен бөтен дөньяга күрсәттеләр. Илебездә халык һәм коммунизм берләште. Социалистик демократиянең чәчәк атуы эшчеләр сыйнфы диктатурасының тагын да ныгуына китерде.

Бу бөек җиңү Ленин—Сталин партиясенең дөрес политикасы белән, партиянең Ленин васиятләрен үтәве белән, партия җитәкчелегендә большевистик юлбашчының иң яхшы сыйфатларын үзендә гәүдәләндергән даһи ленинче, бөек Сталин тору белән тәэмин ителде.

„... Иптәш Ленин безнең илебездәге халыкларның ирекле союзы кирәклек турында, Республикалар Союзы рамкаларында аларның туганнарча бергә эшләүләре кирәклек турында безгә армый-талмый әйтә килде.

Иптәш Ленин бездән киткәндә, безгә, Республикалар Союзын ныгытырга һәм киңәйтергә васият итте. Ант итәбез сиңа, иптәш Ленин, без синең бу васиятеңне дә намус белән үтәрбез!“.

Үткән 16 ел Сталин антын партиянең намус белән үтәгәнлеген күрсәтте.

Бу еллар барсы да Советлар Союзы халыкларының дуслыгы тагын да ныгу һәм чәчәк ату еллары булдылар. Царизм тарафыннан изелеп килгән, патша Россиясендә колониаль-коллар хәлендә яшәгән Урта Азия һәм Закавказье халыклары—үзбәкләр, төрекмәннәр, грузиннар, әрмәннәр, казаклар һәм башка халыклар—бай һәм культуралы тормышта яши башладылар. Милли республикаларның үзләренең социалистик промышленностьлары үсте; колхозлар ныгыдылар һәм крестьяннәргә таза тормыш тәэмин иттеләр; үзләренең интеллигенция кадрлары үсте; милли сәнгать гөрләп чәчәк ата. Халыкларның Сталинчыл дуслыгы, электә артта калган халыкларга рус пролетариатының булышлыгы аларны күтәрде һәм социалистик җәмгыятебезнең алгы сафларына чыгарды. Милли республикаларда социалистик төзелешнең уңышлары һәм культураның үсүе нәтиҗәсендә союзный республикалар саны 11 гә җитте. Ленин—Сталин милли политикасының җиңүләре безнең Конституциябездә закон тәртибендә беркетелде. Бу Конституция һәрбер милли республикадагы һәрбер гражданинның Советлар Союзының тулы хокуклы гражданины икәнлеген, дәүләт властының югары органының—СССР Верховный Советының һәрбер карары, закон көченә кергәнчегә кадәр, Милләтләр Советында каралырга һәм кабул ителергә тиешлекне нык итеп билгели. Милләтләр Советында исә барлык милли республикаларның, өлкәләрнең һәм округларның вәкилләре утыра.

Көнбатыш Украина һәм Көнбатыш Белоруссия хезмәт ияләрен поляк паннары изеүеннән азат итү—Сталин политикасының иң гүзәл җиңүләреннән берсе. 13 миллион украинлылар һәм белоруслар күптән көтелгән азатлыкны алдылар һәм совет халыкларының дус семьясенә кушылдылар.

Ленин гробы янында биргән антында иптәш Сталин әйтте:

„Ленин Кызыл Армияне ныгыту һәм аның хәлен яхшырту безнең партиябезнең иң мөһим бурычларыннан берсе булып тора дип безгә күп тапкырлар күрсәтте... Ант итик, иптәшләр, без үзебезнең Кызыл Армиябезне, Кызыл Флотыбызны ныгыту өчен көчләребезне кызганмабыз“.

Үткән 16 ел, Сталин җитәкчелегендәге партиянең Кызыл Армияне ныгыту бурычын бик яхшы итеп тормышка ашырганлыгын, бу антны да намус белән үтәгәнлеген күрсәтте.

Хәзерге заманның сугыш техникасы белән коралланнуы ягыннан һәм сугышчыларының мораль-политик дәрәҗәләре ягыннан дөньяда безнең армиябезнең тиңдәше юк. Үзенең сугыш сыйфатларын ул Хасан күле районында да, Монголия чигендә дә күрсәтә алды. Көнбатыш Украинага һәм Көнбатыш Белоруссиягә Кызыл Армия азат итүче армия булып килде һәм аны хезмәт ияләре шатланып каршы алдылар. Бүген Кызыл Армия Финляндия халкына хиянәтчеләрдән азат булуда ярдәм итә, Финляндияне тоташтан һәм ваклап саткан һәм Англия — Франция империалистлары кушуы буенча СССР га каршы империалистик һөҗүм хәзерләү өчен Финляндияне плацдармга әйләндерергә маташкан хиянәтчеләр шайкасыннан азат булуда булышлык итә.

Англия—Франция сугыш уты кабызучыларының безнең Ватаныбызны империалистик сугышка өстерәп кертергә күп тапкырлар маташулары Сталинчыл ерактан күрүчән тышкы политика аркасында фаш ителделәр һәм җимерелделәр. СССР белән Германия арасында дуслык турында договор төзелү белән Европадагы бу ике гаять зур дәүләт арасындагы дошманлык бетерелде һәм Европаның көнчыгышында озакка сузылган тынычлык тәэмин ителде. Ләкин Англия—Франция реакциясе СССР ны сугышка тарту өчен тагын да маташып карамас дип уйлау тирән ялгышлык булыр иде. Англия—Франция провокаторлары һәм сугыш уты кабызучылары үзләре тарафыннан башланган империалистик сугышның канлы пожарын яңа урыннарга, беренче чиратта Европаның төньягына җәелдерергә бик нык тырышалар. Без сак булырга тиешбез! Капиталистик чолганыш яшәгәндә Кызыл Армиянең көчен һәм куәтен, совет разведкасын ныгытырга кирәк. Иптәш Сталин әнә шулай өйрәтә.

Кызыл Армия һәм совет халкы бер бөтен булып тоташты. Эшче-Крестьян Кызыл Армиясенең, Кызыл Флотның, Совет Авиациясенең гаять зур көче һәм куәте совет патриотизмының тиңдәшсез күтәрелүенә нигезләнгән. Безнең Кызыл Армиябез меңнәрчә геройларны, бигрәк тә герой очучыларны, җиңелмәслек Сталинчыл лачыннарны тәрбияләде. Киләчәктә аның сафларыннан тагын меңнәрчә һәм меңнәрчә геройлар чыгарлар.

Иптәш Сталин антында әйтелә:

„Иптәш Ленин бездән киткәндә, безгә, Коммунистик Интернационал принципларына турылыклы булуны васият итте. Ант итәбез сиңа, иптәш Ленин, без бөтен дөнья хезмәт ияләренең союзын—Коммунистик Интернационалны ныгыту һәм киңәйтү өчен үзебезнең тормышыбызны аямабыз!“

Үткән 16 ел, Сталин җитәкчелегендәге большевиклар партиясенең бу антны да намус белән үтәгәнлеген күрсәтте.

Бу еллар эчендә кардәш компартияләрне большевиклаштыру буенча гаять кыен эш эшләнде. Күп кенә илләрдә сектантлык ялгышларыннан азап чиккән, аз санлы интеллигентлар группаларыннан эшчеләр сыйнфы, крестьяннәр һәм хезмәтчел интеллигенция белән якыннан һәм көндәлек элемтәдә булган массовый коммунистлар партияләре үсеп чыкты. Коммунистик партияләрнең эше нәтиҗәсендә чит илләрдәге хезмәт ияләре массасы бара торган вакыйгаләрнең мәгънәсен төшенәләр һәм Европадагы сугышның Англия—Франция империалистлары тарафыннан оештырылганлыгын һәм башланганлыгын аңлыйлар. Советлар Союзында большевиклар партиясенең бердәмлеге һәм куәте тиңдәшсез ныгу—Коммунистик Интернационал бердәмлегенең һәм тупланганлыгының һәм аның алдагы җиңүләренең нигезе.

Ленин идеяләре, Ленин хыяллары бүген социализмның җир шарының алтыдан бер өлешендәге җиңүләрендә тормышка ашырылды. Ильич үлгәннән соң үткән 16 ел—ул, Ленин васиятләрен үтәү еллары, Ленин эшләренең тантанасы еллары.

Ленин социализмның җиңүләрендә, совет халкының бердәмлегендә һәм тупланганлыгында, Кызыл Армиябезнең җиңелмәслегендә, Советлар Союзы халыкларының бөек дуслыгында, Ленин—Сталин партиясенең тиңдәшсез куәтендә, пролетар революциянең бөек рулевое иптәш Сталинның даһи җитәкчелегендә яши.

Г. КОНСТАНТИНОВСКИЙ.

РӘСЕМДӘ: „1917 нче ел, РСДРП (б) ның хәрби оешмалары киңәшмәсендә В. И. Лениннең чыгышы“. В. И. Ленин Үзәк музеенә яңа гына алынган картиналардан художник Е. Владимирский эше. (Союзфото).

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫНЫҢ УКАЗЫ

Украина ССР ның һәм Белоруссия ССР ның көнбатыш өлкәләреннән СССР Верховный Советына депутатлар сайлау көне турында

1. Украина ССР ның Волын, Дрогобич, Львов, Ровно, Сталниславов һәм Тарнополь өлкәләреннән һәм Белоруссия ССР ның Барановичи, Белосток, Брест, Вилейка һәм Пинский өлкәләреннән СССР Верховный Советына депутатлар сайлау көнен 1940 нчы елның 24 нче мартына билгеләргә.

2. Бу өлкәләрдән СССР Верховный Советына сайлау кампаниясе 1940 нчы елның 24 нче гыйнварыннан башлана дип игълан итәргә.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе ***М. КАЛИНИН.***

СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре ***А. ГОРКИН.***

Москва, Кремль.
20 гыйнвар, 1940 ел.

Украина ССР ның һәм Белоруссия ССР ның көнбатыш өлкәләреннән Союз Советына һәм Миллэтлэр Советына сайлаулар буенча сайлау округлары төзү

СССР Верховный Советы Президиумының Указы белән, Украина ССР ның көнбатыш өлкәләреннән Союз Советына сайлаулар буенча 20 нче гыйнварда 27 сайлау округы һәм Белоруссия ССР ның көнбатыш өлкәләреннән Союз Советына сайлаулар буенча—16 сайлау округы төзелде.

СССР Верховный Советы Президиумының указы белән, Украина ССР ның көнбатыш өлкәләреннән Милләтләр Советына сайлаулар буенча 20 нче гыйнварда 6 сайлау округы һәм Белоруссия СССР ның көнбатыш өлкәләреннән Милләтләр Советына сайлаулар буенча—6 сайлау округы төзелде. (ТАСС).

ФЕРГАНӘ ТӘҖРИБӘСЕН РЕСПУБЛИКАБЫЗНЫҢ ЮЛЛАР ТӨЗЕЛЕШЕНӘ КҮЧЕРИК!

ЗУР КҮТӘРЕНКЕЛЕК БЕЛӘН

Ферганә каналы төзелешенең бай тәҗрибәсен республикабызның юллар төзелешенә күчерү турында „13 лет Октября“ авыл хуҗалыгы артеле колхозчыларының мөрәҗәгате Столбище районында гаять зур күтәренкелек белән каршыланды һәм колхозчылар массасының гаять көчле производство активлыгын тудырды. Бу хәрәкәткә әледән-әле яңа колхозлар кушылалар һәм үзләренә конкрет йөкләмәләр алалар.

Районның партия һәм совет оешмалары массаның бу активлыгын күтәреп алган хәлдә, юллар хуҗалыгын тулы тәртипкә китерү мәсьәләсенә игътибарны моңа кадәр булганга караганда күп көчәйттеләр. Юлларны төзеклеккә китерү һәм бу эштә Ферганә тәҗрибәсен куллану мәсьәләсе шушы көннәрдә ВКП(б) район комитетының бюро утырышында каралды. Бу утырыш хезмәт ияләре депутатларының район Советының башкарма комитет членнары белән берлектә үткәрелде.

Бюро утырышы юл төзелешенә җитәкчелек итүне турыдан-туры үз кулына алды һәм моның өчен биш кешелек махсус комиссия төзеде. ВКП(б) райкомының икенче секретаре иптәш Петров бу комиссиянең председателе итеп сайланды.

Юл төзелеше мәсьәләләрен тикшерүгә багышланып, 24 нче гыйнварда комсомолның район җыелышы, ә 26 нчы гыйнварда авыл советлары һәм колхоз председательләре, шулай ук колхоз бригадирларының партактив белән берлектә район киңәшмәсе чакырыла. ВКП(б) һәм ВЛКСМ райкомнары иң яхшы коммунистларны һәм комсомолецларны юл төзү участкыларына беркетәләр. Алар монда юл төзүчеләр арасында политик-массовый эшне оештыручы агитаторлар булачаклар.

ИНЖЕНЕР-ТЕХНИК РАБОТНИКЛАР ҖАВАБЫ

„13 лет Октября“ колхозы колхозчыларының мөрәҗәгатен Татарстан Совнаркомы янындагы юллар төзү идарәсенең инженер-техник работниклары үзләренең гомуми җыелышында зур активлык белән тикшерделәр. Җыелыш, гүзәл хәрәкәткә бердәм рәвештә кушылганлыгын белдерде һәм колхозчылар инициативасын зур күтәренкелек белән яклады.

Җыелышта бер тавыштан кабул ителгән резолюциядә болай диелә: „Культуралы һәм төзек юллар өчен башланган гүзәл хәрәкәт—ул илебезнең экономика һәм оборона куәтен тагын да ныгытуга, юллар төзү эшенең халык хуҗалыгының кызу адымнар белән үсеш темпыннан артта калучылыгын бетерүгә юнәлдерелгән. Чкаловск трактын төзек һәм үрнәк хәлгә китерүдә без, инженер-техник работниклар, якыннан торып катнашуны һәм бу хәрәкәтнең большевистик киң колач алуына һәр яклап булышлык итүне ышандырабыз. Ферганә каналы төзелеше тәҗрибәсен ныклап үзләштергән хәлдә, теоретик белемебезне практикада кулланырбыз һәм төзек, культуралы юллар өчен башланган хәрәкәтнең алгы сафында булырбыз“.

Стахановчылар мәктәпләрен барлык районнарда да оештырырга

Соңгы елларга кадәр колхозчылар агротехниканы башлыча агротехника түгәрәкләрендә өйрәнеп килделәр. Түгәрәкләр бу өлкәдә зур урын тоттылар һәм алар хәзер дә шундый ук әһәмияткә ия булып торалар. Ләкин, шуның белән бергә, хәзер, колхоз производствосында агротехника чаралары хәл иткеч урын алган вакытта, колхозчыларның белем дәрәҗәсе торган саен күтәрелгән бер вакытта агротехника түгәрәкләре генә безне канәгатьләндерә алмыйлар. Хәзерге практика колхозларда стахановчылар мәктәпләрен оештыру бурычын алга куйды. Ленинград, Смоленск өлкәләрендә һәм Алтай краенда стахановчылар мәктәпләре масса күләмендә оештырылып эшкә керештеләр. Алтай краеның ключевский районында 110 урында стахановчылар мәктәбе эшли.

Соңгы вакытта Татарстанның да күп кенә алдынгы колхозларында стахановчылар мәктәпләре оештырылды. Калинин районында бу мәктәпләр 7 колхозда оештырылган. Һәрбер мәктәптә 30—40 кеше укый. Алар арасында стахановчы колхозчылар, бригадирлар һәм башкалар бар. Укучыларның 30—40 проценты хатын-кызлар. Занятиеләр үткәрү өчен һәрбер мәктәпкә агрономнар һәм зоотехниклар беркетелгән.

Мәктәпләрдә занятиеләр биш көнгә бер тапкыр программа буенча уздырылалар. Программа 72 сәгатьлек итеп төзелгән. Шуның 36 сәгате кырчылык темасына, 26 сәгате терлекчелек темасына һәм 10 сәгате агымдагы политика мәсьәләләренә бирелгән. Агымдагы политика буенча программада күрсәтелгән темаларга лекцияләрне ВКП(б) райкомы тарафыннан билгеләнгән махсус кешеләр ясыйлар. ВКП(б) райкомы стахановчылар мәктәпләренең эшенә турыдан-туры үзе җитәкчелек итә.

Занятиеләр теге яки бу колхозда язгы чәчүгә хәзерлекнең барышына бәйләп уздырылалар. Шуның нәтиҗәсе буларак, мәктәпләр колхозларда эшне яхшыртуга, язгы чәчүгә уңышлы хәзерлекне тәэмин итүгә нык ярдәм итәләр. Менә Октябрьнең XXII еллыгы исемендәге колхозның мәктәбе. Монда кар тоту турында уздырылган дәрестән соң бу эштә булган җитешсезлекләр бетерелде. Шулай ук чәчү орлыкларын саклауда булган җитешсезлекләрне бетерүдә дә мәктәп нык ярдәм итте. Стахановчылар мәктәпләрендә уздырылган занятиеләрдән соң бригадирлар һәм колхозчылар үз эшләрендә җаваплылыкны арттырдылар. Алар үз эшләренә тәнкыйть күзе белән карый башладылар һәм булган җитешсезлекләрне бетерү өчен җидди чаралар күрәләр.

Стахановчылар мәктәпләре колхозчыларны агрономия һәм зоотехника белеме белән коралландыру белән бергә, колхоз производствосындагы барлык эшләрне үрнәк булырлык итеп оештыруны, беренче чиратта, язгы чәчүгә яхшы хәзерләнүне тәэмин итү өчен хезмәт итәргә тиешләр. Бу мәктәпләрдә занятиеләрне эчтәлекле һәм кызыклы итеп уздыруга нык әһәмият бирергә кирәк. Стахановчылар мәктәпләренә хатын-кызларны тартуга аеручә әһәмият бирергә кирәк. Мәктәпләрдә укучы стахановчы-колхозчылардан үз эшләре турында әледән-әле лекцияләр тыңлауны куллану яхшы нәтиҗәләр бирәчәк.

Стахановчылар мәктәпләрен һич кичекмәстән барлык районнарда да оештырырга кирәк.

Агроном *Х. Шаһиев.*



РӘСЕМДӘ: „1905 нче ел, гыйнвар көннәрендә Николаевск күперендә“ (хәзер бу күпер лейтинант Шмидт исемендә)—художник М. И. Авилов рәсме (Ленинград).

(ТАСС фотохроникасы).

Петербург шәһәрендә патша армиясе тарафыннан коралсыз эшчеләр демонстрациясен аттыруга бүген 35 ел тулды. РӘСЕМДӘ: 1905 нче ел, 22 (9) гыйнвар көне Васильев атавында.

(Художник Моковский картинасыннан).

(ТАСС фото-клишесе).

„КАНЛЫ ЯКШӘМБЕ“

XIX нчы йөз азагында Европада башланып киткән промышленность кризисы Россияне дә чолгап алды. 1900—1903 нче елларда өч меңләп фабрика һәм завод ябылды. 100 меңнән артык эшче урамга ташланды. Эшчеләрнең хезмәт хакы бик нык кимеде. Рус-япон сугышы хезмәт ияләренең хәлен тагын да начарлатты. Патша самодержавиесе белән Япония Манчжурия һәм Корея өчен сугыштылар. Сугышучы якларның һәрберсе бу илләрне үз колониясенә әйләндерергә теләде. Патша хөкүмәтен бу сугышка буржуазия һәм алпавытлар этәрде. Алар товар урнаштыру өчен яңа базарлар эзлиләр иде. Патша хөкүмәте империалистик сугышны үзенең өстенлеген ныгыту һәм өлгереп килгән революцияне туктату теләге белән башлады.

Патша Россиясе „иң кешелексез, иң вәхши формасындагы һәр төрле—һәм капиталистик, һәм колониаль һәм хәрби—изүләрнең учагы“ булды (Сталин, „Ленинизм мәсьәләләре“, 5 нче бит).

Пролетариат капиталистик эксплоатациядән һәм политик хокуксызлыктан газап чикте. Фабрика һәм заводларда эш көне 12—14 сәгатькә җитте һәм аннан да артты. Хезмәт хакы чиктән тыш түбән булды. Эшчеләргә әледән-әле штрафлар салынды. Аларны фабрика кибетләреннән югары бәя белән начар сыйфатлы, еш кына бозык продуктлар сатып алырга мәҗбүр иттеләр. Стачкалар, сүз, матбугат, җыелышлар һәм союзлар ирекe турында сүз дә булырга мөмкин түгел иде. Патша Россиясе тарихка халыклар төрмәсе булып керде. Эшчеләр үзләренең сыйнфи интереслары өчен көрәшкә күтәрелделәр. XX нче йөз башы политик стачкаларга әверелгән экономик стачкалар белән характерлана.

Патша хөкүмәте стачкачыларны рәхимсез рәвештә җәзалады: аларны камчыладылар, төрмәләргә утырттылар, каторгага җибәрделәр, атып үтерделәр. Шуның белән бергә патша хөкүмәте, эшчеләр хәрәкәтен революцион бурычлардан читләтергә теләп, бу хәрәкәт белән шаярырга маташты. Патша хөкүмәте камчылау һәм юмалау политикасы үткәрде.

Хөкүмәт заданиесе буенча Московның охранка бүлеге начальнигы Зубатов Москвада һәм Петербургта, эшчеләрнең интересларын яклау дигән булып, „Эшчеләрнең ярдәмләшү җәмгыяте“н оештырды. Патша охранкасы, үзенең агентлары аркылы, патша хөкүмәте эшчеләрнең экономик таләпләрен канәгатьләндерүдә ярдәм итәргә хәзер тора дигән булып, аларны ышандырырга тырышты. Зубатовчылар: патша эшчеләр ягында торгач нигә инде политика белән маташырга, нигә инде революция ясарга“ диделәр.

Ләкин бу чаралар эшчеләр хәрәкәтен туктата алмадылар. Ул үсте һәм полиция оешмаларын үз юлыннан себереп ташлады.

1904 нче ел ахрында революция хәрәкәтенең яңа дулкыны күтәрелде. Япониягә каршы сугыш хезмәт ияләре массасының җәфалануын көчәйтте һәм патша самодержавиесенең бөтен черeклеген һәм сатлыклыгын ачты.

Патша революцияне сугыш белән буарга теләде, ләкин аның үзе өчен көтелмәгән нәтиҗәләр килеп чыкты. Рус-япон сугышы революцияне тизләтте. 1904 нче елның декабрендә иптәш Сталин оештырган һәм җитәкчелек иткән, атаклы Баку стачкасы бөтен Россиядәге эшчеләрнең массовый чыгышлары өчен сигнал булды. „Бу стачка бөек революцион давыл алдыннан яшнәгән яшен шикелле булды“ („ВКП(б) тарихының кыскача курсы“, 64 нче бит).

Бөек революцион давыл 1905 нче елның 9 нчы гыйнварында башланды. Путилов заводында дүрт эшченең урыннан чыгарылуына җавап итеп, Путилов эшчеләре 3 нче гыйнварда забастовка игълан иттеләр. Башка фабрикаларның һәм заводларның эшчеләре дә аларга кушылдылар. 8 нче гыйнварда гомуми стачка башланды. Петербургның 150 меңгә якын эшчесе забастовкада катнашты. Патша хөкүмәте стачканы эшчеләр канына батырырга карар бирде. Патша охранкасы агенты поп Гапон патша хөкүмәтенә ярдәмгә килде. Эшчеләрне революцион көрәштән читләтү теләге белән Гапон 1904 нче елны ук Петербургда „рус фабрика-завод эшчеләре җыелышы“н оештырган иде. Демагогия һәм алдау юлы белән Гапон эшчеләр арасында авторитет казана алды. Стачка вактында провокатор Гапон эшчеләргә петиция белән патшага барырга тәкъдим итте. Гапончылар петиция яздылар һәм бу петиция күп кеше катнашкан җыелышларда тикшерелде. Бу җыелышларда большевиклар да сөйләделәр. Большевиклар йогынтысы астында петициягә политик таләпләр кертелде: учредительный собрание чакыру, сүз, матбугат, җыелышлар, союзлар һәм стачкалар ирекe, сигез сәгатьлек эш көне, чиркәүне дәүләттән аеру, җирне крестьяннәргә бирү һәм башкалар.

Җыелышларда сөйләгәндә большевиклар азатлыкны үтенүләр белән алырга мөмкин түгеллекне, аны кулга мылтык тотып яулап алырга кирәклекне эшчеләргә аңлаттылар. Ләкин ул вакытта әле эшчеләр патшага ышаналар иде, илне буудa дөреслекне патшадан яшерүче патша чиновниклары гаепле дип саныйлар иде. „Революциягә кадәрге Россиянең аңсыз эшчеләре патшаның хаким сыйныф башлыгы икәнлеген, ягъни меңнәрчә җепләр аркылы эре буржуазиягә бәйләнгән һәм үзләренең монополияләрен, өстенлекләрен һәм табышларын барлык көчләү чаралары белән сакларга хәзер торучы эре җир биләүчеләр башлыгы икәнлеген белмиләр иде“ (Ленин, XIX том, 344 нче бит).

Үзләренең речьләрендә һәм листовкаларында большевиклар эшчеләргә петиция белән патша сараена бару файдасыз һәм куркыныч икәнлекне аңлаттылар. Алар „Бетсен патша самодержавиесе“ дигән лозунг куйдылар. Ләкин Кышкы сарайга баруны инде туктату мөмкин түгел иде. Эшчеләрнең петициясендә болай диелгән иде: „Без, Петербург шәһәре эшчеләре, безнең хатыннарыбыз балаларыбыз һәм ярдәмчесез карт ата-аналарыбыз, хакыйкать һәм яклау эзләп, патша, синең яныңа килдек. Без хәерчеләндек, безне изәләр, безгә көч җитмәслек хезмәт йөклиләр, безне мыскыл итәләр, безне кешегә санамыйлар... Без түзеп тә карадык, ләкин безне хәерчелек, хокуксызлык һәм наданлык баткаклыгына торган саен тирәнрәк этәрәләр, деспотизм һәм баш-баштаклык безне буа... Түзеп торуның чиге килеп җитте. Безнең өчен, һич түзеп булмаслык газап чигүләрне дәвам иттерүгә караганда үлү яхшырак булган момент килеп җитте...“.

Ә шул арада патша һәм аның хөкүмәте эшчеләрне кан белән каршыларга хәзерләнде. Петербургка төрле яктан гаскәрләр китерелде. Эшчеләр Кышкы сарайны җимерергә һәм патшаны үтерергә телиләр дип солдатларны ышандырдылар. Шәһәрнең барлык районнарына һәм бигрәк тә күперләр янына гаскәри частьләр куелды. Петербург хәрби лагер төсенә керде.

9 (22) нчы гыйнварда якшәмбе көн эшчеләр үзләренең хатыннары һәм балалары белән бергә, иконалар һәм патша портретлары күтәреп, патша сараена бардылар. Сарай мәйданына ун меңнәрчә эшчеләр җыелды һәм алар патшаның чыгуын көттеләр. Солдатлар эшчеләргә каршы тезеп куелдылар. Көтмәгәндә хәрби боргы уйналды. Аның артыннан мылтыклардан, беренче, икенче, өченче залп бирелде. Ату искәрмәстән башланды. Үтерелгән һәм яраланган уннарча эшчеләр урамда ятып калдылар.

Канлы җәзалау бөтен Петербургда: Нарва капкасы янында, олы Дворянский урамда, Шлиссельбург трактында һәм башка урыннарда барды. Картларны да, балаларны да, хатын-кызларны да кызганмадылар. „Үзенең кая һәм ни өчен баруын һәр кемгә алдан ук белдереп, коры кул белән барган дошманына каршы батыр генераллар „уңыш белән“ хәрәкәт иттеләр... Бу—яклаучысыз һәм тыныч халык массасын иң кабахәт рәвештә, салкын кан белән үтерү иде“ (Ленин, VII нче том, 87 нче бит).

Петербург урамнары канга батты. Меңнән артык кеше үтерелде, ике меңнән артык кеше яраланды. Коралсыз эшчеләрне, аларның хатыннарын һәм балаларын ату бер үк вакытта патшага булган ышанычны да ату булды. Эшчеләр, иконаларны һәм патша портретларын типкәләп ташлап, „Алла юк, патша юк“, дип кычкырдылар.

9 нчы гыйнварда иртә белән эшчеләр әле патшага ышанган булсалар, кичен инде ни туры килсә шуның белән коралланып, алар патшага һәм аның сарай өеренә каршы көрәшкә, баррикадаларга бардылар. Большевикларның йогынтысы бик нык үсте. Пролетариатның революцион тәрбияләнүе бер көн эчендә генә дә шул кадәр алга китте ки, тыныч тормыш айларында һәм елларында да ул бу кадәр атлый алмаган булыр иде.

Томскида иптәш Киров җитәкчелегендә кораллы демонстрация үткәрелде. Бу демонстрацияне казаклар һәм полиция таратты.

Варшавада эшчеләр бердәмлек забастовкасы игълан иттеләр. Ул бер атнага якын дәвам итте. 16 (29) нчы гыйнварда Варшавада демонстрация булып, ул да эшчеләр канына батырылды.

„Патшаның канлы явызлыгы турындагы коточкыч хәбәр бөтен җиргә таралды. Бөтен эшчеләр сыйныфын, бөтен илне ачулану һәм нәфрәтләнү чолгап алды. Патшаның явызлыгына каршы протест билгесе итеп эшчеләр забастовка ясамаган һәм политик таләпләр куймаган шәһәр калмады“ („ВКП(б) тарихы“, 65—66 нчы битләр).

Петербургдагы „Канлы якшәмбе“ дән соң ук РСДРП ның Кавказ Союз Комитетының „Кавказ эшчеләре, үч алырга вакыт“ дигән прокламациясендә иптәш Сталин, революцион давыл күтәрелә, пролетариат, ә аның белән бергә крестьяннәр патша самодержавиесенә үзләренең нәфрәтләрен белдерделәр һәм алар, аны тәмам җиңгәнгә кадәр сугышырлар, дип язды. Иптәш Сталин болай диде: „Россия—аз гына селкенүдән дә атылуы мөмкин булган, корылган һәм курогы күтәрелгән мылтык. Шулай, иптәшләр, рус революциясе җилкәннәрен күтәрәчәк һәм ләгънәт патшаның кабахәт тәхетен „җир йөзеннән себереп ташлаячак“ вакыт ерак түгел. Безнең бурычыбыз—шундый моментка хәзер тору...“ (Л. Берия, „Закавказьедәге большевистик оешмаларның тарихы турындагы мәсьәләгә карата“, 3 нче басма, 49 бит).

Патшаның ерткычларча җәзалавына Россиянең эшчеләр сыйныфы стачкалар дулкыны белән җавап бирде. 10 (23) нче гыйнварда Москвада, 11(24) нче гыйнварда Вильнода, Гельсингфорста, 13(26) нче гыйнварда Ригада стачкалар башланды.

1905 нче елның гыйнварында илдә 440 мең (1905 нче елга кадәр булган 10 ел эчендә булганнан артыграк) эшче забастовка ясады. Күп кенә урыннарда эшчеләрнең революцион демонстрацияләре булды. Пролетариатның кораллы чыгышлары да булды.

Россиянең барлык промышленность үзәкләрендә эшчеләр „Бетсен самодержавие!“, „Яшәсен демократик республика!“, „Яшәсен 8 сәгатьлек эш көне!“ дигән лозунглар белән чыктылар.

Ленин болай дип язды: „Пролетариатның көрәше илле-йөз миллионлы крестьяннәр массасы эчендә зур чуалыш һәм бер кадәр революцион хәрәкәт тә тудырды, крестьяннәр хәрәкәте армиягә дә йогынты ясады һәм солдатларның восстаниеләренә, армиянең бер өлеше белән икенче өлеше арасындагы кораллы бәрелешләргә китерде. Шулай итеп, 130 миллион халыклы бик зур ил революциягә керде, шулай итеп, йокымсыраучы Россия революцион пролетариат һәм революцион халык Россиясенә әверелде“ (Ленин, XIX нчы, том 345 нче бит).

Революцион хәрәкәтнең башында Ленин җитәкчелегендәге большевиклар партиясе торды. Гыйнвар вакыйгаләреннән соң, кораллы восстание хәзерләү бурычын большевиклар беренче планга куйдылар.

Меньшевиклар, шул исәптән Троцкий да, кораллы восстаниегә каршы булдылар. Алар пролетариатны революция юлыннан реформалар юлына борып җибәрү өчен бөтен көчләрен бирделәр.

⁂

Гыйнвардагы канлы вакыйгалардән бирле утыз биш ел үтте. 1905 нче ел „Канлы якшәмбе“ белән башланды һәм Красная Пресня баррикадалары белән, Москвада декабрьдәге кораллы восстание белән тәмам булды. 1905 нче ел революциясе эшчеләр һәм крестьяннәр канына батырылды, ләкин царизм үзенең һәлакәтен кичектерде генә. 1905 нче ел революциясе эзсез калмады, ул Россиядәге хезмәт ияләренең азатлык өчен көрәш тарихында гаять зур роль уйнады. 1905 нче елның „генеральный репетиция“ сеннән башка Октябрь Социалистик революциясенең җиңүе мөмкин булмас иде, диде Ленин.

„Канлы якшәмбе“дән соң утыз биш ел вакыт үтте, Советлар Союзының эшчеләр сыйныфы һәм хезмәт ияләре, большевиклар партиясе җитәкчелегендә, башында иптәш Сталин торган хәлдә, илебездә социализм төзеп, ышанычлы һәм кыю адымнар белән алга—коммунизмга баралар.

Д. Борисов.

Дәүләт көнчыгыш культуралары музее (Москва) „Кытай сәнгате“ күргәзмәсе. Художник Пань Юнь картинасыннан репродукция.

Г. Широков фотосы.
(ТАСС фото-клишесе).

М. Ю. ЛЕРМОНТОВ ИСТӘЛЕГЕН МӘҢГЕЛӘШТЕРҮ

СССР Халык Комиссарлары Советы русның бөек шагыйре М. Ю. Лермонтовның истәлеген мәңгеләштерү буенча Бөтенсоюз Комитеты оештырырга карар бирде. М. Ю. Лермонтовның үлүенә 1941 нче елда 100 ел тула.

Бөтенсоюз Комитетының председателе итеп А. А. Фадеев, председательнең урынбасарлары итеп Н. Н. Асеев һәм О. Ю. Шмидт расландылар. Бөтенсоюз Комитетының членнары итеп К. Е. Ворошилов, А. А. Жданов, Н. С. Хрущев, А. С. Щербаков, А. Я. Вышинский, Н. А. Булганин, А. Ф. Горкин, П. Н. Поспелов, П. А. Тюркин, Л. З. Мехлис, П. С. Попков, В. Л. Комаров, А. Н. Толстой, М. А. Шолохов, А. С. Орлов, И. К. Луппол, П. И. Лебедев-Полянский, Н. Л. Мещеряков, Б. М. Эйхенбаум, Д. Д. Благой, В. Я. Кирпотин, Н. Л. Бродский, М. Б. Храпченко, П. Г. Антокольский, В. В. Иванов, В. И. Лебедев-Кумач, А. А. Прокофьев, И. Л. Сельвинский, П. А. Павленко, Н. С. Тихонов, Ю. Н. Тынянов, К. И. Чуковский, А. Т. Твардовский, В. И. Немирович-Данченко, И. М. Москвин, В. В. Барсова, И. Л. Андроников, П. И. Чагин, П. Тычина, Я. Купала, Г. Н. Леонидзе, Самед Вургун, Г. Сарьян, Х. Алимҗан, Җамбул, Дехоти, К. Маликов, Дурды Клыч, Шәриф Камал, Фәррах, Шогенцуков, Яндиев, Г. Плиев, Г. Цадасс, Т. Цуг, К. Кочкаров, Х. Плиев, Ф. И. Беззубова расландылар.

Бөтенсоюз Комитетына М. Ю. Лермонтовның истәлеген мәңгеләштерү һәм аның иҗадын киң рәвештә популярлаштыру буенча кирәк булган чараларны билгеләү һәм аларны СССР хөкүмәтенең раславына кертү эшләре тапшырылды. (ТАСС).

АУЧЫ-НАТУРАЛИСТ БЛОКНОТЫННАН

БҮРЕ АВТОМАШИНА АСТЫНДА

Бүреләр өчен гыйнвар ае иң авыр айлардан санала. Ачлык аларны тагын да усалландыра. Авыл читендә күренгән этләр яки абзарларыннан чыгып адашкан сарыклар бүре тырнагыннан котыла алмыйлар. Ләкин хәзер колхоз авылында азык эзләп авыл кырыенда, ындыр артында йөрүче этләрне табуы кыен. Ә колхозның терлекләре нык һәм җылы абзарларда яшиләр.

Тирән кар катлавы бүреләрнең урманда йөрүләренә, куян аулауларына да зур кыенлык тудыра. Еш кына бүреләр азык эзләп ерак юллар үтәргә мәҗбүр булалар.

Тигез шоссе буйлап Таттрансның 22—75 нче номерлы автобусы бара. Пассажирлар йөртү өчен булган бу автобусның тәҗрибәле шоферы Павел Матвеевич Емелин машинаны бик оста алып бара. Автобусның фонарлары юлны еракtan ук яктырталар. Соңгы борылманы үтеп, машина урманнан туры юлга килеп чыга, тизләк көчәя...

Еракта яктылыкта кара нокта күренә. Ул торган саен зурая һәм аның бүре икәнлеге беленә. Бүре яктылыктан качарга теләп машина астына үзе килеп керә.

Шофер иптәш Емелин бүрене Главпушнинаның Казан заготпунктына тапшырып, аның тиресе өчен 80 сум һәм бүләк сыйфатында 100 сум акча алды.

К. Сафонов.

* * *

Тельман исемендәге колхозның (Башкыртстан республикасы, Тәтешле районы, Акбулат авылы) аучылары үзләренең планнарын һәр вакыт арттырып үтәп киләләр. Аучылардан Мөхәмәтгали Рәхимев һәм Галим Шәреттинев иптәшләр җәнлек тиреләре тапшыру буенча 4 нче квартал планын 150 процент итеп үтәделәр.

6 нчы гыйнвар көнне Рәхимев һәм Шәреттинев иптәшләр урманда 3 ана һәм 2 ата бүре аттылар. Алар бүре тиреләрен Союзпушнинаның район бүлегенә тапшырып, тире хакыннан тыш икесенә 400 сум бүләк алдылар.

Х. Миннегалин.

„Кызыл Татарстан“ газетасының киләсе номеры 25 нче гыйнварда чыга.

Чит илләрдә

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

(ТАСС хәбәрләреннән)

Көньяк Кытайда

Кытай гаскәрләренең Кантонга һөҗүме уңышлы бара. Кытайлар японнарның Хуасяннан чигенә торган (Кантоннан төньякта) частьләрен җимерделәр һәм соңгы тәүлектә көньякка таба 10 километр алга киттеләр. Кытай чыганакларыннан алынган мәгълүматларга караганда, бу тирәдәге сугышларда японнарның 5 меңгә якын кешеләре үтерелгән һәм яраланган, ә кытайлар 2 меңгә якын кешеләрен югалтканнар.

Кантоннан төньяк-көнчыгышта, Цунхуа районында, кытайлар инициативаны үз кулларында тоталар. Японнар, кытай гаскәрләренең басымына түзә алмыйча, шоссе буйлап тагын да көньякка таба чигенергә керештеләр. Кытай гаскәрләре соңгы 3 тәүлек эчендә Лунмынь—Цзэнчэн шоссесе буйлап көньякка таба 50 километр алга киттеләр.

Үзәк Кытайда

Хубэй провинциясенең үзәк өлешендә кытайлар Чжунсяннан төньяк-көнбатышта японнарны өч пункттан кысрыклап чыгардылар. Шул ук провинциянең төньяк өлешендә кытай партизаннары Бэйпин—Ханькоу тимер юлы буенда 7 күперне шартлаттылар һәм 50 километр буена тимер юл хәрәкәтен өзделәр.

Төньяк Кытайда

Шаньси провинциясенең көньяк-көнчыгыш өлешендә кытай гаскәрләре отряды 14 нче гыйнварда Чжанцзы шәһәре бистәләренә бәреп керде.

Кытай партизаннары Тайгу районында (Тайюаньнан көньякта) тимер юл участкысын җимерделәр һәм японнарның коммуникацияләрен өзделәр.

Кытай гаскәрләре отряды Кайфынга (Хэнан провинциясенең төньяк өлеше) тагын налет ясады һәм анда полиция йортын, япон гаскәрләре казармасын яндырды. Курчак „хөкүмәт“ нең каршылык күрсәткән полицейскилары тар-мар ителде.

15 нче гыйнварда кытай партизаннары Баодиннан (Хэбэй провинциясе) көньякка таба 150 километрда японнарның гаскәри поездын һәлакәткә очраттылар. Японнар зур югалтулар бирделәр.

Шушы көннәрдә кытай артиллериясе Баотоу тирәсендә (Суйюань провинциясе) разведка очышы үткәрүче япон самолетын бәреп төшерде.

ТӨРКИЯДӘ ҖИР ТЕТРӘҮ

ЛОНДОН, 19 гыйнвар. (ТАСС). Рейтер агентлыгының Истамбулдан хәбәр итүенә караганда, 18 нче гыйнварга каршы төндә Нигдә вилаятендә ике тапкыр көчле рәвештә җир тетрәгән. Җир тетрәү нәтиҗәсендә 50 кеше үлгән һәм 160 кеше яраланган, 400 дән артык йорт җимерелгән.

17 һәм 18 нче гыйнварда Төньяк Анатолия территориясендә 8 тапкыр җир селкенгән.

Караҗаби үзәнлегендә (Бурса вилаяте) 15 авыл су астында калган.

ЕВРОПА СУГЫШЫ

БЕРЛИН, 20 гыйнвар. (ТАСС). Германия армиясенең верховный командованиесе,—Мозель белән Пфальц урманы арасында германнарның разведка отряды французларның разведка отряды белән бәрелеш вактында берничә плен алды, дип хәбәр итә. Германия авиациясе Англия һәм Франция өстендә разведка очышлары үткәргән. Чик буе зонасы өстендә патруль очышлары вактында Франция фронт участкысы турында һава сугышы булган. Германиянең бер самолеты бәреп төшерелгән. 20 нче гыйнварга каршы төндә дошманның берничә самолеты төньяк-көнбатыш Германиягә таба тагын Голландия территориясе аркылы очып үткәннәр.

ПАРИЖ, 20 гыйнвар. (ТАСС). Кичә фронтта һәр ике як авиациясенең хәрәкәтләре булды, дип хәбәр ителә. Германия территориясендә, Блис елгасы районында разведка отрядлары арасында көчле рәвештә атышу бара.

ПАРИЖ, 19 гыйнвар. (ТАСС). Гавас агентлыгы түбәндәгечә хәбәр итә: „Германия гаскәрләре, көчле салкыннар вактында өзелгән разведка эшен яңадан башлап җибәрделәр. Урманлы Вогезы секторында Германиянең 20 кешелек патруле Франция постларының берсенә атака ясады. Һәр ике як сугышны гранаталар белән алып барды. Нәтиҗәдә немецлар, берничә плен калдырып, чигенделәр“.

Америка эшчеләре ак Финляндиягә ярдәм итүгә каршы чыгалар

НЬЮ-ЙОРК, 20 гыйнвар. (ТАСС). „Дейли Уоркер“ газетасының Детройттан (Американың автомобиль промышленносты үзәгеннән) хәбәр итүенә караганда, Крайслерның автомобиль заводында эшчеләр арасында ак Финляндиягә ярдәм фондына акча җыю өчен ящикләр куелган. Эшчеләр ящикләргә акча урнына утиль тутырганнар. Маннергейм бандаларына түгел, бәлки Америка эшсезләренә ярдәм күрсәтү өчен фонд төзүне таләп итеп кайбер ящикләргә лозунглар язылган.

Газетаның аеруча күрсәтеп үтүенә караганда, Америка Кушма Штатларының күп кенә шәһәрләрендә шундый фактлар бик күп булып тора. Ләкин Америка матбугаты алар турында дәшмәүне артык күрә.

Палач Маннергейм турында Американың негрлар газетасы

НЬЮ-ЙОРК, 20 гыйнвар. (ТАСС). Негрларның Нью-Аркда (Нью-Джерси штаты) чыга торган „Нью-Джерси геральд Ньюс“ газетасы Финляндиядә совет гаскәрләренең хәрәкәтләре турында Америка газеталарының ялган хәбәрләренә каршы чыга. Газета болай дип яза: „1919—1920 нче елларда, Маннергейм фин эшчеләрен һәм крестьяннарен үтергән вакытта, фин халкына үзебезнең теләктәшлегебезне белдергән шикелле үк, без фин халкының азатлык көрәшенә чын теләктәшлек белдерәбез. 1919—1920 нче елларда Маннергейм Америка, Англия һәм Франция капиталистларыннан корал алды. Алар аңарга, фин халкы азат һәм бәйсез булырга теләгәнлектән, ярдәм күрсәттеләр“.

Норвегия балыкчыларының ак финнәргә ярдәмгә каршы чыгышлары

СТОКГОЛЬМ, 19 гыйнвар. (ТАСС). „Арбейдерен“ газетасы көнчыгыш Финмаркенда (Норвегия) Катейвер поселкысы балыкчыларының митингысы турында хәбәр итә. Катейвер балыкчылары үзләренең резолюцияләрендә Норвегия реакциясенең советка каршы кампания алып баруына протест белдерәләр һәм Норвегиянең нейтралитетын саклау өчен кирәк булган эшләрнең барсын да эшләвен һәм ак финнәргә ярдәм оештыруга каршылык күрсәтүен хөкүмәттән таләп итәләр.

Резолюциядә болай әйтелә: „Без Финляндиянең халык хөкүмәте белән һәм Советлар Союзы белән үзебезнең бердәмлегебезне белдерәбез һәм Маннергейм өеренә булышлык күрсәтүгә каршы протест игълан итәбез“.

АНГЛИЯДӘ ЭШСЕЗЛЕКНЕҢ ҮСҮЕ

БЕРЛИН, 19 гыйнвар. (ТАСС). „Фелькишер беобахтер“ газетасы, Англия статистикасының соңгы мәгълүматларына караганда, Англиядә эшсезләр саны 1 миллион 340 мең кешегә җитә, дип яза. Сугыш башланганнан бирле эшсезләр саны ай саен уртача йөз мең кешегә артып тора. Эшсезләр саны, 2 миллион кешенең мылтык астында булуына һәм сугыш промышленностының бөтен тәүлек буена эшләвенә карамастан, һаман үсә.

Американың сугыш кораллары сатучысы:

— Әһә, Европа сугышы вактында, мин инде тулыланырга өлгердем...

М. Старов рәсме.
(ТАСС фото-клишесе).

КЫТАЙ ФРОНТЛАРЫНДАГЫ СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕН КҮЗӘТҮ

Чит ил хәбәрчеләренең Чунцинда 18 нче гыйнварда булган матбугат конференциясендә кытай гаскәрләре командованиесенең вәкиле Көньяк һәм Үзәк Кытай фронтларында сугыш хәрәкәтләре турында күзәтү белән чыкты.

Көньяк Кытайдагы фронтта, Кантон секторында, японнарга каршы һөҗүмгә күчкән кытай гаскәрләренең удары астында япон гаскәрләренең 2 нче гыйнварда башланган чигенүе дәвам итә. Кытай гаскәрләре, японнарны эзәрлекләгән хәлдә, 10 нчы гыйнварда Лунмынь—Цинюань линиясенә (Кантоннан төньяк-көнчыгышта һәм төньяк-көнбатышта) чыктылар. Хәзер кытайлар кайбер юнәлешләрдә Кантоннан 30—35 километрда торалар. Шулай итеп, Кантоннан төньякка таба японнар тарафыннан башланган һөҗүм җимерелү белән тәмам булды. Японнар бик күп кешеләрен һәм сугыш кирәк-яракларын югалттылар һәм, тулысынча тар-мар ителүдән котылу өчен, үзләренең элекке позицияләренә бик тиз чигенергә мәҗбүр булдылар. Аннан тыш, японнар шулай ук үзләре тарафыннан элек алынган пунктларның бер өлешен, мәсәлән, үз вактында Кантонда японнар оборонасының тышкы линиясендә терәк пунктлар булып хезмәт иткән Цунхуа һәм Хуасянь (Кантоннан төньяк-көнчыгышта һәм төньякта) пунктларын ташлап китәргә мәҗбүр булдылар.

Наньнин секторында (Гуанси провинциясе) японнарның беренче хәрәкәтләре 5 нче дивизия частьләрен китерүдән башланып китте, ләкин зур югалтулар аркасында, бу дивизия үз алдына куелган бурычларны үти алмады. Ул гына да түгел, бу дивизия тулысынча бетерелү куркынычы алдында торды. Япон командованиесе шул вакытта бу районга Формоза гаскәрләре бригадасын җибәрде. Ләкин моннан соң да, япон командованиесе тарафыннан куелган бурыч—Биньянны алу бурычы—үтәлмәде. Бу секторда японнарның сугыш хәрәкәтләре нәтиҗә бирмәделәр. Гуньлиньгуань дигән тау аралыгы (Наньнин—Биньян шоссесендә) өчен сугышлар кытай гаскәрләренең җиңүе белән тәмам булды. Кытайлар, японнарны бередән дүртенче тапкыр кысрыклап чыгарган хәлдә, 31 нче декабрьдә Гуньлиньгуаньны үз кулларында калдырдылар гына түгел, бәлки, 4 нче гыйнварда Цзютанны алып, алга да киттеләр. Хәзер японнар бу районга бер дивизия чамасы өстәмә көч китерделәр. Японнарның өстәмә көчләре Наньнин районына таба барган вакытта, кытайлар коммуникацияләрне өзәләр һәм япон командованиесен үз гаскәрләрен тәэмин итү мөмкинлегеннән мәхрүм итәләр.

Үзәк Кытайдагы фронтта әһәмиятле үзгәрешләр булмады. Тунчэн районында (Хубэй провинциясенең көньяк өлеше) японнар, Пуцидан һәм Цзуняннан өстәмә көчләр алып, актив операцияләр башладылар, ләкин, зур югалтулар биреп, бу участкыда сугыш хәрәкәтләрен туктатырга мәҗбүр булдылар.

Хубэй провинциясенең үзәк өлешендә японнар 11 нче һәм 12 нче гыйнварда Чжусян районында төньяк-көнбатыш юнәлешендә һөҗүм башладылар. Кытайлар, бирегә тиз арада үзләренең резервларын китереп, японнарның һөҗүм итүче частьләрен чигендерделәр.

Чунцин, 20 гыйнвар. (ТАСС).

Җаваплы редактор
Һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.

ТАТАРСТАН АССР ФИНАНС ХАЛЫК КОМИССАРИАТЫ БЕЛДЕРӘ:

Барлык предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар 1939 нчы елның икенче яртысында эшчеләрдән, хезмәткәрләрдән һәм шулар хокукында булган башка кешеләрдән доход налогы һәм культура җыемы чигереп калу турында, шушы ел 25 нче гыйнвардан да соңга калмыйча, тиешле район (шәһәр) финанс бүлегенә түбәндәге форма буенча отчет бирергә тиешләр:

______ районы / шәһәре — Отчет формасы № 47—а

______ (предприятиенең, учреждениенең, оешманың исеме)

Расчет бүлегенең адресы ______

Эшчеләрдән һәм хезмәткәрләрдән налог алу буенча район финанс бүлегенең регистрация №

1939 нчы елның икенче яртысында эшчеләрдән, хезмәткәрләрдән һәм шулар хокукында булган башка кешеләрдән доход налогы һәм культура җыемы чигереп калу турында

ОТЧЕТ

1. Отчет елының азагында эшчеләрнең һәм хезмәткәрләрнең саны.

2. Налог һәм культура җыемы түләргә тиешле эшчеләр һәм хезмәткәрләр составы хезмәт хакының отчет бирү ярты елында тотылган фондын (средстволардан, бюджеттан һәм башкалардан файдалану буенча).

3. Болардан тыш, отчет ярты елында шул предприятие, учреждение һәм оешманың эшчеләре һәм хезмәткәрләре исемлегендә булмаган кешеләргә түләнгән хезмәт хакы, авторлык гонорары һәм уйлап табу, шулай ук техниканы яхшырту буенча бирелгән бүләкләү сумалары (налог һәм культура җыемы түләүченең категориясен күрсәтеп) һәм счетлар буенча түләнгән сумалар.

	Доход налогы	Культура җыемы
4. Отчет ярты елында чигереп калынган суманың барлыгы		
Шул исәптән: а) исемлектә булган эшчеләрдән һәм хезмәткәрләрдән		
б) ул предприятиенең, учреждениенең эшчеләре һәм хезмәткәрләре исемлегендә булмаган кешеләрдән		
5. Отчет ярты елында район финанс бүлегенең счетына кертелгән сума		

Предприятиенең, учреждениенең, оешманың җитәкчесе:

Баш бухгалтеры:

120—1

КАЗАН ШӘҺӘР ТРАМВАЙ ИДАРӘСЕ
кондукторлар, вагон йөртүчеләр һәм слесарьлар хәзерләү курсларына
УКУЧЫЛАР АЛА

Уку сроклары: кондукторлар хәзерләү курсларында—20 көн. Стипендия айга 75 сум. Вагон йөртүчеләр курсларында—ике ай ярым. Стипендия айга 90 сум. Слесарьлар хәзерләү курсларында—2 ай. Стипендия айга 90 сум.

Курсларга 18 яшь тулган һәм аннан югары яштәге кешеләр кимендә 4 класс күләмендәге белем белән алыналар. Ялгызларга, медицина тикшерүе комиссиясе үткәннән соң тулай торакта урын бирелә.

Гаризалар шушы ел, 1 нче февральгә кадәр алына. Документлар белән гариза җибәрү өчен адрес: Казан, Ершов кыры, 1, бүлмә № 6. 121—3—1

ТАТАРСТАН АССР ФИНАНС ХАЛЫК КОМИССАРИАТЫ БЕЛДЕРӘ:

СССР Совнаркомының 1935 нче ел, 13 нче май карары һәм СССР Финанс Халык Комиссариатының 1939 нчы ел, 29 нчы декабрьдә чыгарган 830-169 нчы номерлы һәм 1940 нчы ел, 11 нче гыйнварда чыгарган 22-7 нче номерлы күрсәтмәләре нигезендә, Татарстан АССР территориясендәге барлык учреждениеләрнең, предприятиеләрнең һәм оешмаларның җитәкчеләре үзләренең 1940 нчы ел өчен расланган штатларын, ставкаларын һәм хезмәт хакы фондларын 1940 нчы ел, 1 нче июньгә кадәр тиешле финанс органнарында теркәтергә тиешләр.

Төзелеш, монтаж оешмаларының (трестлар, управлениеләр, конторлар) һәм эшләрен хуҗалык юлы белән алып баручы төзелешләрнең җитәкчеләре үзләренең штатларын шушы ел, 1 нче мартка кадәр теркәтергә, ә подрядный юл белән эш алып баручы төзелешләрнең, шулай ук проект һәм геолого-разведка оешмаларының җитәкчеләре үзләренең штатларын шушы ел, 15 нче апрельгә кадәр теркәтергә тиешләр.

Күрсәтелгән сроклар үткәннән соң Дәүләт Банкысы органнары хезмәт хакы түләү өчен кирәкле сумаларны бары 1940 нчы елда штатларын теркәтү турында бирелгән регистрация карточкасын күрсәтү буенча гына бирәчәк.

ТАТНАРКОМФИН.

114—2—1 114—2—1

Киров районындагы
Культура сараенда
23 һәм 24 нче гыйнварда
РЕВИЗОР
Талоннар: 23 ндә 44, 45 һәм 24 ндә 46, 47.
Спектакль кич сәгать 8 дә башлана.

Галиәсгар Камал исемендәге
Татар Дәүләт Академия театры
Бүген, 22 нче гыйнварда спектакль булмый.
23 һәм 24 нче гыйнварда
КҮЗЛӘР
Талоннар: 101, 102.
25 һәм 26 нчы гыйнварда
КЫЮ КЫЗЛАР
Талоннар: 103, 104.
Спектакльләр кич 7 сәгать 30 минутта башлана. Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

КИРӘК:

Микробиология институтына (Зур Красный урам, 65) ВЕТЕРИНАРИЯ ВРАЧЫ, КОЧЕГАР һәм производство бүлеге өчен ӨЛКӘН БУХГАЛТЕР. 104—3—3

Бондюг заводына, баш энергетик хезмәтләрен үтәү өчен, ПРАКТИК ЭШ СТАЖЛЫ ИНЖЕНЕР-ЭНЕРГЕТИК. Гариза белән бергә белгеч үзенең белгечлеге буенча эш стажы турында белешмә бирергә тиеш. Татарстан АССР, Бондюг заводы, кадрлар бүлеге. 124—3—1

Казандагы 4 нче тегермәнгә ГРУЗЧИКЛАР, ҖЫЕШТЫРУЧЫЛАР, ПЛАНОВИК, КАССИР һәм ПОЖАРДАН САКЛАУ РАБОТНИКЛАРЫ. Башка урыннардан килгән ялгыз эшчеләргә тулай торакта урын бирелә. Казан, Ярминкә урамы, 20. 122—1

„Торгречтранс“ның Казан конторасына, бүлекләр һәм базалар өчен ӨЛКӘН БУХГАЛТЕРЛАР, шулай ук ЭКОНОМИСТЛАР, КАРТОТЕКАЧЫ һәм ИНСТРУКТОР-КУЛИНАР. Куйбышев урамы, 7 (ишек алдыннан керергә). 108—3—2

Таткоопинсоюзга, Казанда һәм районнарда эшләү өчен, БАШ һәм ӨЛКӘН БУХГАЛТЕРЛАР. Хезмәт хакы килешү буенча. Казан, Чернышевский урамы 2. 107—3—3

Казан Фото-желатин заводына даими эшкә ХЕЗМӘТНЕ ОЕШТЫРУ БҮЛЕГЕ НАЧАЛЬНИГЫ, ПЛАННАР БҮЛЕГЕ НАЧАЛЬНИГЫ, МОНТАЖ БУЕНЧА СМЕТАЧЫ-ТЕХНИК һәм авто-атлы транспортка НОРМАЛАУЧЫ. Хезмәт хакы килешү буенча. Тору урыны бирелә. Казан, Восстание бистәсе, Фото-желатин заводы. 79—2—2

„Химзаготлес“ трестының агач материаллары хәзерләү буенча өлкәара Казан конторасына, ашыгыч рәвештә, контора аппаратында эшләү өчен ӨЛКӘН РЕВИЗОР, Мари АССР һәм Киров өлкәсе районнарында эшләү өчен ӨЛКӘН БУХГАЛТЕР УРЫНБАСАРЛАРЫ һәм БУХГАЛТЕРЛАР. Казан, Кызыл Армия бистәсе, Зур урам, 62. Баш бухгалтерга килергә. Телефон 42—06. 92—3—2

Главлесосбытның Казан конторасына, Татарстан һәм Чувашстан республикалары районнарында даими рәвештә эшләү өчен БРАКЕРЛАР. Казан, Колхоз урамы, 13. Телефон 13—65. 93—2—2

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ
22 нче гыйнварда спектакль булмый.
23 нче гыйнварда көндез һәм кич, шулай ук 24 нче гыйнварда кич
БАКЧАЛАР ЧӘЧӘК АТА
23 нче гыйнварда
талоннар: көндез 17, кич 82.
Спектакльләр кич 7 сәгать 30 минутта башлана. Билетлар көндез 11 сәгать 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 8 сәгать 30 минутка кадәр кассада сатыла.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ
Бүген һәм һәр көн зур программа буенча зур цирк уены.
Москва 4 нче труппасының гастрольләре
ИНТЕРМЕДИЯ
ЧИК ЙОЗАКТА
Кич 8 дә башлана.
АНОНС: РСФСР ның атказанган артисты орденлы
ЗОЛОТО гастрольләре
Атнаның икенче көнендә цирк эшләми.
Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 1 гә һәм кич 5 тән 8 гә кадәр ачык.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	ЛЕНИН 18 нче ЕЛДА
„УНИОН“ 12, 2, 4, 6, 8, 10 да.	ЛЕНИН ОКТЯБРЬДӘ
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ“ 6, 8 һәм 10 да	БӨЕК ТАҢ
„ЧАТКЫ“ 6, 8 һәм 10 да.	МЫЛТЫКЛЫ КЕШЕ
„ПИОНЕР“ 11, 1, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Көндез МИТЬКА ЛЕЛЮК Кич ЛЕНИН ТУРЫНДА ӨЧ ҖЫР. Көндез 1 сәгаттә мәктәпкә кадәр яшьтәге балалар өчен сеанс.
„РОТ-ФРОНТ“ 4, 6, 8, 10 да.	ЛЕНИН 18 НЧЕ ЕЛДА
КУЛЬТУРА САРАЕ 4-30, 7, 9-30 да.	БӨЕК ГРАЖДАНИН (Икенче сериясе)

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 2488 ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА, ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 307.